**Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениясе Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре “Катнаш төрдәге 3нче “Айсылу” балалар бакчасы**

**Раслады:**
МББМБУ РТ Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре “Катнаш төрдәге 3нче“Айсылу” балалар бакчасы мөдире вазыйфасын башкаручы, өлкән тәрбияче
_____________Р.Х.Исламова
“31” август 2021 ел

**Педагогик киңәшмәдә кабул ителде**

Беркетмә № 1
“31” август 2021 ел

# Эш программасы

Зурлар төркеме

Тәрбиячеләр: Калимуллина В.Ш.

Кирамова Г.Р.

2021-2022 нче уку елы



1

## Эчтәлек

**I. Кереш өлеш**
1.1 Аңлатма язуы........................................................................................ ...............3
1.2 5-6 яшьлек балаларның психик үсешенең яшь үзенчәлекләре ..............................4
1.3 Зурлар төркеме эшчәнлегенең юнәлешләре............................................................. 5
1.4 Эш программасының максаты һәм бурычлары........................................................5
1.5 Программа материалларын үзләштерү буенча көтелгән нәтиҗәләр........................6
1.6 Этномәдәни төбәк бердәмлеге..................................................................................... ..8
1.7 Көндәлек режим..........................................................................................................11
1.8 Белем бирү эшчәнлеге челтәре...................................................................................12
**II. Белем бирү өлкәләре буенча комплекслы-тематик план**
2.1 Танып белү үсеше.........................................................................................................13
2.2 Социаль- коммуникатив үсеш......................................................................................41
2.3 Сөйләм үсеше..................................................................................................................44
2.4 Нәфис-нәфасәти үсеш ....................................................................................................62
2.5 Физик үсеш......................................................................................................................78
**III. Ата-аналар белән эш**..............................................................................................79
**IV. Кулланылган әдәбият**..............................................................................................82

**I. Кереш өлеш**

**1.1.Аңлатма язуы**

Бу программа "Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына Федераль дәүләт белем бирү стандарты"на нигезләнеп, Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге "Туганнан мәктәпкә кадәр" төп гомуми мәктәпкәчә яшьтә белем бирү программасына, балалар бакчасының еллык эш планына таянып төзелде.

Программаның төп максаты -мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы кыйммәтле яшәеше өчен уңай шартлар тудыру , шәхес культурасының нигезле җирлеген формалаштыру, шәхси һәм яшь үзенчәлекләренә яраклаштырып, физик һәм психик сыйфатларны төрле яклап үстерү, баланы хәзерге җәмгыятьтә яшәргә, мәктәптә укырга әзерләү, мәктәпкәчә яшьтәге баланың куркынычсыз яшәү рәвешен булдыру.

Бу максатлар бала эшчәнлегенең (уен, аралашу, хезмәт, танып-белү, иҗади, уку) төрле процессларында тормышка ашырыла.

Бурычлар:

1. Балаларның аң һәм физик үсешенең табигый процессына уен, аралашу, танып-белү, хезмәт, хәрәкәт, матур әдәбият уку, музыка- иҗат, ясау эшчәнлеге.
2. Белем өлкәләрен үзләштергәндә психологик һәм педагогик яктан ярдәм итү.
3. Режим моментларында, ирекле белем бирү , мөстәкыйль, ата-аналар белән эш вакытында зурлар-кечкенәләр бердәм (партнерлык) эшчәнлеген оештыру.

Программа куйган максатларга ирешүдә түбәндәгеләр беренче әһәмияткә ия:

-һәр баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яклы үсеш алуы турында кайгырту;

-балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;

-балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен киң куллану; укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү;

-тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;

-балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану; белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү (интегральләштерү);

-мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;

-гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм, гомумән, мәктәпкәчә учреждение тормышында катнашуын тәэмин итү;

-балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага кирәгеннән артык акыл һәм физик эш йөкләмәү аксатыннан дәвамчанлыкны саклау-региональ якын килүне гамәлгә ашыру

Эш программасы үз эченә баланың һәрьяклап үсүен, аларның яшь һәм шәхсимөмкинлекләрен исәпкә алып төзелгән 5 төрле үсеш юнәлешен ала: социаль – коммуникатив үсеш, танып белү үсеше, сөйләм үстерү, сәнгати үсеш, физик үсеш.

Программаны тормышка ашыру срогы - 1 ел (2021-2022 уку елы)

**1.2. 5-6 яшьлек балаларның психик үсешенең яшь үзенчәлекләре.**

Алтынчы яшьтәге балалар уен башланганчы рольләрне бүлешә һәм эш-гамәлләрне яраклаштырып төзи беләләр. Уендагы мөнәсәбәтләр эчтәлек һәм интонация ягыннан алган рольгә туры килүче сөйләм белән үрелеп бара. Балаларның реаль мөнәсәбәтләре вакытындагы сөйләм рольдәге сөйләмнән аерыла. Балалар социаль мөнәсәбәтләрне үзләштерә һәм олыларның төрле эшчәнлекләрдәге буйсынучанлык позициясен аңлый башлыйлар. Бер төрле рольләр аларны башкалары белән чагыштырганда күбрәк җәлеп итә. Рольләрне бүлешкәндә, рольләр арасындагы субординация белән бәйләнгән каршылыклар килеп чыгарга мөмкин. Уен тирәлеген оештырганда, мәгънәви яктан «үзәк» һәм «периферия» аерымлануы күзәтелә («Сырхауханә» уенында табиб кабинеты, «Чәчтараш» уенында чәч кисү залы шундый үзәк, ә көтү залы уен тирәлегенең перифериясе сыйфатында була). Балаларның уендагы эш-гамәләре күптөрлеләнә.Бу яшьтә балаларның сынлы сәнгать белән кызыксынулары аеруча көчәя. Алар бик еш рәсем ясый башлыйлар.Балалар рәсем ясарга сәләтле. Рәсемнәр эчтәлекләре ягыннан бик күптөрле: аларда балаларның тормыштан алынган тәэсирләре дә, уйлап чыгарылган ситуацияләр дә, фильм һәм китапларга иллюстрацияләр дә чагылырга мөмкин. Гадәттә, рәсемнәр төрле объектларның схематик сурәтләре характерында була, ләкин композиция чишелешенең оригинальлеге белән аерылырга, хәрәкәтсез һәм үсештәге мөнәсәбәтләрне чагылдырырга да мөмкин. Рәсем сюжетлы характер ала, күп тапкыр кабатланучы аз гына яки җитди үзгәрешләре булган сюжетлар бик еш
очрый. Кеше сурәте детальләштерелгән һәм пропорциональрәк була бара. Рәсем буенча, сурәтләнгән кешенең җенесе һәм эмоциональ хәле турында әйтеп була.

Конструкцияләү бу эшчәнлек өчен шартларны анализлый белүләре белән характерлана.

Балалар агач конструктор детальләрен кулланалар һәм атыйлар. Булган материал белән корылманың детальләрен алыштыра алалар. Үрнәк төзелешне гомуми ысул белән тикшерә беләләр. Төзисе корылманың төп өлешләрен күрсәтә алалар. Конструкцияләү эшчәнлеге схема
нигезендә, үзләре уйлап яки шарт буенча эшкә ашырыла ала. Күмәк эшчәнлек барышында конструкцияләү барлыкка килә.

Балалар, берничә (2, 4, 6) тапкыр бөкләп, кәгазьдән, шулай ук табигый материаллардан конструкцияли алалар.

Алар конструкцияләүнең 2 ысулын үзләштерәләр: 1) табигый материалдан сәнгати образ тудыру (бу очракта балалар, табигый материалларны төрле детальләр белән тулыландырып, бербөтен образ тудыралар); 2) сәнгати образдан чыгып табигый материалтабу (бу очракта бала образны тудыру өчен кирәкле табигый материал сайлый).

Төсне, форма һәм зурлыкны, предметларның төзелешен аңлау, кабул итү камилләшә бара.

Балаларның күзаллаулары системалаштырыла. Балалар төп төсләр һәм аларның төсмерләрен генә түгел, ә арадаш төсләрнең төсмерләрен дә, шулай ук турыпочмак, овал, өчпочмакларның формаларын да аералар һәм атыйлар. Бер дистә предметны зурлыклары буенча рәткә тезеп куя алалар.

Бу мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен кабул итү сәләтенең төрле ситуацияләрдә, бигрәк тә бер үк вакытта берничә капма-каршы билгеләрне истә тотарга кирәк булган очракта, аерым авырлыклар тудыруын күрсәтә.

Зурлар төркемендә образлы фикер йөртү үсеше дәвам итә. Балалар күрсәтмә пландамәсьәләне чишәргә генә түгел, хәтта объектны үзгәртергә, объектларның нинди эзлеклелектә бер-берсе белән бәйләнешкә керү мөмкинлекләрен күрсәтергә һ.б. да сәләтле.

Бу яшьтә уйлап чыгару сәләте үсү балаларга шактый оригиналь һәм эзлекле киңәйтелгән хикәяләр уйлап чыгарырга мөмкинлек бирә. Балаларның әлеге сәләте бары тик бу юнәлештә махсус эш алып барганда гына актив рәвештә үсәчәк.

Балаларның игътибар тотрыклылыгы үсә. Алар шулай ук игътибарларын кирәк юнәлешкә бора һәм башкага күчерә ала башлыйлар. Ирексез игътибардан аңлы игътибарга күчү күзәтелә.
Сөйләм, шул исәптән аның аваз ягы камилләшү дәвам итә. Балалар сызгырулы, чыжылдаулы һәм сонор авазларны дөрес әйтә башлыйлар. Шигырьләр укыганда, сюжетлы-рольле уеннар вакытында һәм көндәлек тормышта фонематик ишетү сәләте, сөйләмнең сәнгатьлелеге үсә, грамматик төзелеше камилләшә. Балалар барлык сүз төркемнәрен кулланалар, сүз уйлап чыгару белән актив шөгыльләнәләр. Сүз байлыклары арта. Синоним белән антонимнар актив кулланышка керә. Бәйләнешле сөйләм үсә. Балалар эчтәлекне дә, рәсемнәр буенча да иң мөһимен генә түгел, ә детальләрне дә кертеп сөйли ала башлыйлар.
Бу яшьнең казанышлары түбәндәгеләр белән характерлана: уен эшчәнлегендә рольләр бүлешү; уен пространствосын төзи белү; югары нәтиҗәлелеге белән аерылып торган рәсем эшчәнлегенең алга таба үсеше; конструкцияләүдә үрнәкне карап гомумиләштерә белү. Зиһенгә алу объектларнын катлаулы формаларын анализлау белән характерлана; фикерләү чараларын (схемалы, комплекслы күзаллаулар, цикллы үзгәрешләр турында күзаллаулар) үзләштерү белән бергә фикер йөртү сәләте үсә, гомумиләштерү күнекмәләре, уйлап чыгару сәләте, тотрыклы
игътибар, сөйләм, *м и н* образы үсә.

**1.3.Зурлар төркеме эшчәнлегенең эш юнәлеше.**

Төркемдә белем бирү процессы комплекслы һәм яңа парциаль программалары кулланылып үткәрелә:
Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге ”Туганнан мәктәпкә кадәр”төп гомуми мәктәпкәчә яшьтә белем бирү комплекслы программасы
Программа “Иң гади математик күзаллаулар булдыру”, “Сөйләм телен үстерү” бүлегеннән тыш тулы күләмдә кулланыла.
Парциаль программалар:
1. 1.З.Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина, Ф. В. Хәзрәтова «Математикага өйрәнәбез»Казан Татарстан китап нәшрияты 2013,
2. “Туган телдә сөйләшәбез”: методик әсбап /Ф.В.Хәзрәтова,
3.”Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны юлларда үзләрен хәвефсез тоту кагыйдәләренә өйрәтү дәресләре циклы”. Методик күрсәтмәләр/ Авт.-төз.: Г.А.Галеева һ.б.- Казан:”Балаларның тормыш иминлеге фәнни үзәге”ДУ нәшрияте, 2010

**1.4. Эш программасының максаты һәм бурычлары**

**Эш программасының максаты:**
Балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып мәктәпкәчә яшьтәге балаларныңфизик, интеллектуаль, шәхси сыйфатларын үстерү.

**Эш программасының бурычлары**:
- Һәр баланың физик һәм психик сәламәтлеген, аларның физик үсешен, эмоциональ иминлеген саклау һәм ныгыту
- Уен, аралашу, хезмәт, танып белү, нәтиҗәле ,иҗади-музыка, нәтиҗәле эшчәнлек, уку кебек төрле эшчәнлектә зурлар һәм балаларның узара бәйләнешен булдыру.
- Уку эшчәнлегенә нигез салу.
- Һәр баланың шәхси үзенчәлекләрен үстерү һәм саклау өчен педагогик ярдәм күрсәтү.
- Баланың тулы үсешен булдыру максатыннан гаиләләр белән узара бәйләнеш, ярдәм итешү

Эш программасының төп фикере - укыту, тәрбияләү, сәламәтлеген саклау белән бергә баланың шәхесен үстерү.
Эш программасының күрсәткече:
*Белем өлкәләрен интеграцияләү нигезендә тулы педагогик процессны төзү;
*Балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып төп юнәлешләр – физик,

социаль-шәхси, танып белү-сөйләм, сәнгати үсеш юнәлешләре буенча төрле яклап үстерү;

*Балаларның иҗади сәләтен ачу, сәләтлеләрне табу, шәхси үстерү өчен яңа технологияләр куллану;

*Балаларның мөмкинчелегеннән, кызыксынучанлыгыннан, сорауларыннан чыгып төрле эшчәнлекләрне үстерү;

*Эчтәлекле аралашуга, сөйләшүгә төзелгән шәхси һәм төркем белән эшчәнлекләр оештыру;

*Балага эшчәнлектә үзен күрсәтү, эчтәлеген сайлау, иптәшләр сайлау хокукы.

Эш программасын төзү өчен алынган принциплар һәм алымнар мәктәпкәчә белем бирү учреждениясенең гомуми белем бирү программасына тулысынча туры килә.

**1.5.Программа материалларын үзләштерү буенча көтелгән нәтиҗәләр.**

**1. Физик үсеш юнәлеше буенча**:

Дөрес хәрәкәт техникасын саклап йөрү һәм йөгерү, гимнастика стенасының һәр аратасына басып менү, бер аралыктан икенче аралыкка күчү; төрле алымнар белән шуышу; кул чукларына, тезләргә һәм аяк бармакларына, табаннарга һәм уч төпләренә таянып; куллар белән тартыла –тартыла корсакта шуышу. Баскан җирдән биеклеккә сикергәндә, башлангыч торышка дөрес басу, җиргә дөрес төшү; баскан җирдән озынлыкка сикерү (кимендә 70 см). 1,5 м арадан ыргытылган тупны кул чуклары белән тотып алу; ыргыткан вакытта дөрес тотып алу, предметларны уң һәм сул куллар белән төрле ысуллар ярдәмендә ыргыту; тупны җиргә бәреп сикертеп тору (кимендә 5 тапкыр рәттән). Статик һәм динамик тигезлек саклауга күнегүләр башкару; колоннага берәрләп, икешәрләп (пар булып), түгәрәк ясап тезелү; Мөстәкыйль рәвештә бозлы юлчыкта шуу, эздән чаңгыны шудырып йөрү, 500м ара узу; урында як – якка борылышлар ясау; кечерәк тауга күтәрелү. Ике көпчәкле велосипедта йөрү, борылышлар ясау; тирә – юньдә ориентлаша белү; уң һәм сул якларны белү; хәрәкәтле уеннарның вариантларын уйлап табу, мөстәкыйль уйнау; хәрәкәтләрнең матурлыгын, нәзакәтлелеген, сыгылмалылыгын күрсәтеп, кемгәдер (нәрсәгәдер) охшатып күнегүләр башкару.Культура – гигиена күнекмәләрен дөрес башкару.

**2.Танып белү үсеше юнәлеше буенча:**

Бина эчендә, мәйданчыкта, урамда үзләрен әйләндереп алган төрле предметларның исемнәрен, кулланылышларын белү, аларның сыйфатларын, үзенчәлекләрен әйтү. Үзләре күрмәгән һәм күрү мөмкинлеге булмаган әйберләр, вакыйгалар белән кызыксыну булдыру, предметның тарихы белән кызыксыну. Үзенең гаиләсе, гаиләдәге традицияләре турында горурланып сөйләү; төркемдә, балалар бакчасында үткәрелә торган, аерым алганда , өлкәннәрне дә, балаларны да шатландыруга юнәлдерелгән чараларда актив катнашу. Үзенең туган шәһәре турында сөйли белү, үскәч кем булырга хыялллануы турында сөйләү. Хезмәт кешесе турында, аның шәхси һәм эшлекле сыйфатлары, эш – гамәлләре хакында сөйләү. Берничә йорт хайванын, кыргый җәнлекне белү һәм атау; үсемлекләрне, хайваннарны, балыкларны, кошларны күзәтү. Әйләнә – тирә турында иң гади нәтиҗәләр чыгара һәм алган тәэсирләр белән уртаклаша белү. Әйләнә – тирә дөнья белән үзара дөрес бәйләнештә булу. Үсемлекләр, хайваннар, кошлар, балыкларны күзәтүдә катнашу һәм аларны тәрбияләүдә көчтән

килгән кадәр булышу; тере һәм тере булмаган табигать турында белемнәр белән уртаклашу; үсемлекләрне өзмәү, агач – куакларны сындырмау; тереклек ияләренә сакчыл караштә булу, аларга зыян китермәү.

Бертөркем предметларның ничә өлештән төзелгәнен, үзенчәлекле билгеләрен (төсен, формасын,зурлыгын) әйтә белү, 10 кә кадәр санау (микъдар саны), “Барлыгы ничә?” дигән сорауга җавапбирә белү.Предметларны парлап кую юлы белән ике төркемне чагыштыру. Төрле озынлыктагы, киңлектәге, биеклектәге ике предметны арта һәм кими бару тәртибендә урнаштыра белү; һәр предметның зурлыгы турында сөйләү. Өчпочмак, түгәрәк, турыпочмаклык, квадрат; шар, куб,цилиндрны тану һәм әйтеп

бирү; аларның үзенчәлекле билгеләрен (аерымлыкларын) күрә белү, тирә – юньдә әлеге фигураларга охшаш предметларны табу. Үзенә карата предметларның торышын сүзләр белән аңлатып бирү (уңда, сулда, алдымда, артымда, өстә, аста).Уң һәм сул кулларны аера белү. Тәүлек вакытларын әйтә белү.

**3.Социаль – коммуникатив үсеш юнәлеше буенча:**

Бергәләп уйнау вакытында үзенә роль ала, рольдә үз – үзеңне тота белү; рольләр арасында буйсынулы бәйләнешне саклау (сатучы – сатып алучы) һәм кара – каршы сөйләшү алып бару; уенны башлап җибәрә, яңа рольләр яисә гамәлләр тәкъдим итә, сюжетны баета белү. Өстәл уеннары вакытында алып баручы ролен башкару (ел ахырына), иптәшләренә уен кагыйдәләрен аңлата белү. Театрда (курчак, драма) сәнгати образны чынбарлыктагыча кабул итү. Мөстәкыйль сәхнәләштерелгән уеннарда уен өчен урын әзерли белү; нәфис сәнгати чаралар (хәрәкәтләр, интонация, мимика), атрибутлар, реквизитлар кулланып, рольгә керә белү. Театраль һөнәрләр турында мәгълүматлы булу.

**4.Сөйләм үстерү юнәлеше буенча:**

Балаларның тормыш тәҗрибәсендә очрамаган предметлар һәм күренешләрне белдерүче сүзләр исәбенә сүзлек запасын арттыру, эмоциональ халәтне (ачулы, моңсу), этик сыйфатларны (хәйләкәр, юмарт), предметларның билгеләрен һәм үзенчәлекләрен белдерүче сүзләрне актив кулланылышка кертү. Антонимнарны сөйләмдә аңлап куллану; сүз ясагыч кушымчаларярдәмендә яңа сүз ясалу очракларын белү (тәм – тәмле). Авазларны дөрес әйтү өстендә аңлап эшләү, сүздә беренче авазны аерып әйтә белү, сәбәп – нәтиҗә бәйләнешләрен төшенү. Сөйләмдә тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрне куллану; сюжетлы рәсемнәрнең эчтәлеге турында тулы, мәгънәле итеп сөйли белү; исем, өлкәннәр ярдәмендә, уенчыкны тасвирлап сөйләү үрнәкләренкабатлау, таныш әсәрләрдән өзекләрне сәхнәләштереп сөйләү.Бала фантазиясенең көчле үсеше нәтиҗәсе буларак, кеше ышанмаслык вакыйгалар уйлап чыгарып сөйләү. Үз эшчәнлеген (уенда, көнкүрештә һәм башка эш – гамәлдә) актив сөйләм белән бергә алып бару.

Аерым бер әдәби әсәрне тыңлыйсы килү теләген әйтә белү; балалар китапларының иллюстрацияләрен кызыксынып карау. Яраткан әкиятне атый белү, ошаган шигырьне яттансөйли алу; уен вакытларында санамыш ярдәмендә уенны алып баручыны сайлау (өлкәннәр күзәтүе астында). “Әсәр ошадымы?”, “Әсәрдә бигрәк тә кем ошады һәм ни өчен?”, “Кайсы өзекне кабат укырга?” кебек сорауларга аңлап җавап бирү.

**5. Нәфис-нәфәсәти үсеш юнәлеше буенча:**

**Рәсемдә***:* предметларны, күренешләрне карандаш, буяулар, фломастерлар, төсле акбурлар кулланып сурәтләү, төсләрне дөрес сайлап, пөхтә итеп буяу. Бер рәсемдә берничә предметны берләштереп, катлаулы булмаган сюжет төзү. Дымково, Филимоново бизәкләре белән уенчык силуэтларын бизәү.

**Әвәләүдә***:* Өйрәнгән барлык алымнарны кулланып, төрле предметлар һәм уенчыклар әвәләү, аларны коллектив композициягә берләштерү.

**Кисеп ябыштыруда***:* Кайчыны дөрес тотып, турыга (квадрат һәм турыпочмаклык) һәм диагональ буенча кисү; квадраттан – түгәрәк, турыпочмаклыктан овал кисү (почмакларын җайлап кына кисеп алып). Берничә кисәктән торган предметларның сурәтләрен пөхтә итепябыштыру. Предметларның төсләрен туры китереп яисә үз теләгең белән төсләр сайлау, үсемлек орнаменты яки геометрик фигуралар кулланып бизәкләр төзү.

**Конструкцияләүдә***:* Төзелеш детальләрен конструкцияләү үзенчәлекләренә карап куллану. Тәрбияче әйткән бирем буенча, корылмаларны төрлечә үзгәртү, турыпочмаклы кәгазь битен урталай бөкли белү.

**1.6. Этномәдәни төбәк бердәмлеге (ЭРС)**

Балаларның туган илгә карата белемнәрен һәм дәүләт(Яңа ел, Ватанны саклаучылар көне, Җиңү көне, 8 Март) халыкара (Сөмбелә , Нәүрүз, Сабантуй) бәйрәмнәре турында белемнәрен арттыру. Туган шәһәрнең күренекле урыннары белән таныштыру. Үз халкыңның кешелеклелеге, кунакчыллыгы, чисталыгы турында мәгълүмат бирү.Татарстан Республикасының гореф-гадәтләре турында уку. Балаларның кызыксынуларын исәпкә алып, туган як табигате турындагы белемнәрен киңәйтү. Кешеләрнең табигатьне саклау буенча эшчәнлеге белән таныштыру. Тере һәм тере булмаган табигатькә сакчыл караш тәрбияләү, табигатьтә үзеңнең катнашыңнан соң туган уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәтү, туган як табигатенә үз ихтыяҗыңны канәгатьләндерү өчен дип карау ярамаганлыгын аңлату, аны файдалануның беренчел күнекмәләрен булдыру («Әгәр мин һәм башка кешеләр дару үләннәрен тамырлары белән җыйса...»). Туган якта ешрак очрый торган үсемлек һәм хайваннарга карата кызыксынуны үстерү. Табигать объектларын үзенчәлекләре буенча классларга һәм төркемнәргә бүләргә өйрәтү (ылыслы һәм яфраклы агачлар, куаклар, үлән үсемлекләр; урман, болын, бакча үсемлекләре; урман җиләкләре, гөмбәләр, бүлмә үсемлекләре (гөлләре); кыргый һәм йорт хайваннары, кышлаучы һәм күчмә кошлар, балыклар, бөҗәкләр һ. б.) Республика территориясендәге хайваннарның яшәү рәвешен, аларның тышкы кыяфәт үзенчәлекләрен (гәүдә өлешләре, тәне нәрсә белән капланган), хәрәкәт итүысулларын (шуыша, оча, йөзә), азыкларын; кайбер бөҗәкләрнең, җир-су хайваннарының,сөйрәлүчеләрнең яшәү мохитенә яраклашуларын күзәтергә өйрәтү. Хайваннарнытавышларыннан таныргa булышу. Туган як табигатенең матурлыгын, аның форма, төс, исләр байлыгын күрә һәм тоя белү күнекмәләрен үстерү.Төрле яшьтәш милләтләренә карата изгелекле һәм хөрмәтле мөнәсәбәт формалаштыру. Татар халкының мәдәниятенә, гореф –гадәтенә кызыксыну уяту. Җырга, сынлы сәнгатькә, әдәбияткә, Идел буе халкының сәнгатенә карата мәхәббәт тәрбияләү.(Россия, Татарстан)

| № | Юнәлешләр | Бурычлар |
|---|---|---|
| 1 | Физик үсеш | Балаларда үз шәһәрләренә карата кызыксынучанлык тәрбияләү.Үзеңнең сәламәтлегеңә, тормышка ашырып,сәламәт тормыш алып барырга стимуллаштырып,үзеңнең халык һәм төрле милләт халкының (Чуваш, Башкортостан, Рәсәй) сөйләм халык иҗатына теләк тәрбияләү. Халык музыкаль хәрәкәтле уеннарга һәм эстафеталарга нигезләнеп төзелгән, балаларда уен шөгыле ндә үзләренең хәрәкәтчәнлекләренә карата үзконтроль үстерү.Татар, рус халык уеннары белән таныштыру.Таныш татар һәм рус халык уеннарын мөстәкыйль оештыра, ахырына җиткерә белергә өйрәтүне дәвам итү. Хәрәкәт осталыкларын, күнегү күнекмәләрен камилләштерү. Сын гәүдә,хәрәкәтләрне аңлап матур, тиз, оста үтәргә камилләштерү. Балаларның хоккей буенча- “Ак барс”, футбол “Рубин”, баскетбол “УНИКС” һ.б. спорт командалары турында күзаллауларын киңәйтү. 2013 елгы Бөтендөнья 27 җәйге Универсиада |

| | | |
|---|---|---|
| | | төзелгән төрле спорт комплекслары белән таныштыру. Әйрән, сөзмә, кымыз кебек файдалы эчемлекләр турында күзаллауларын формалаштыру. |
| | Социаль – коммуникатив үсеш | Әхлакый сыйфатлар турында күзаллауларын формалаштыру: үз халкыңның кешелеклелеге, кунакчыллыгы, чисталыгы; рус халкының гореф-гадәтләрен ихтирам итү.Балалар арасында үзара мөнәсәбәт тәрбияләү: уйнау гадәте,эшчәнләү, олыларны яхшы гамәл, мөнәсәбәт белән шатландыра белүләренә омтылу.<br>Төрле милләт яшьтәшләренә изгелекле мөнәсәбәт формалаштыру.<br>Үз-үзеңә үзлегеңнән һәм сыйфатлы хезмәт күрсәтүне булдыру (киенергә һәм чишенергә, киемнәрне төреп кую)төркемдә һәм балалар бакчасы җирлеген тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү,<br>дежурлар вазифасын үтәү.Коллективта эшләүгә тарту, башка кешеләргә булышу теләге уянуда бүләкләү.<br>Олылар хезмәте, аларның нәтиҗәсе һәм әһәмияте турында күзаллауларын киңәйтү һәм системалаштыру.<br>Татар, рус халыкларының хезмәт гореф-гадәтләре аша балаларга әдәби сәнгать хезмәтнең төрле яклары турында күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү. Хезмәт башкаруда мөстәкыйльлекне, үзсүзлелекне, җаваплылыкны бүләкләү;<br>шәхси һәм коллективлы хезмәттән канәгатьләнү, горурлык хисе белән бүлешү, олылардан һәм яшьтәшләреннән,үз эшендә канәгать уңай билге алуына омтылу .<br>Хәвефле ситуацияләрдән чыгу юллары, беренче ярдәм күрсәтү алымнары белән таныштыруны башлау. Шәһәр юлларында һәм иҗтимагый урыннарда юл йөрү кагыйдәләрен камилләштерү:<br>тыйнак булырга, сабыр, кычкырып сөйләшмәскә, тәртип сакларга, чисталык; иҗтимагый транспортта олыларга һәм кечкенәләргә урын бирергә.Кешегә карата әйләнә - тирәдәге куркыныч ситуацияләрга сакчыл мөнәсәбәт камилләште |
| 3 | Танып белү үсеше | Башка милләт халкына дус-тойгы тәрбияләү. Идел буе халкының тарихы, мәдәнияте, гореф-гадәтләре һәм табигате аша балаларда танып-белү кызыксынуы камилләштерү (Чуваш, Башкортостан). Башкаладагы һәм Татарстандагы башка шәһәрләрне өйрәнгәндә информацион, күрсәтмәле материалларaша карашларын киңәйтү. Татар, урыс, башкорт, чуаш халкының әдәбияте, тел иҗаты белән таныштыру.<br>Татарстан – күп милләтле республика икәне турында күзаллауларын формалаштыру. Казан – зур сәнәгый үзәк, Рәсәйнең иң борынгы шәһәрләренең берсе. Казан республикабызның башкаласы. Казанда президент, Татарстан хөкүмәте, шәһәр мэры эшлиләр.<br>Идел – Кама дәүләт саклаулыгы (заповедник), “Түбән Кама”милли паркы белән танышу, һәм аларның республика табигатен саклауда әһәмияте |
| 4 | Сөйләм үсеше | Мәдәни әңгәмә тәрбияләү.Ике яклы әңгәмә камилләштерү.<br>Көндәлек тормышта олылар һәм балалар белән татарча һәм русча сөйләшү. Матур әдәбият, татар, рус халыкларының тел иҗаты белән таныштыру. Әйтем, мәкальне аңлауларына |

| | | |
|---|---|---|
| | | ирешү,сөйләмдә аларны урынлы һәм мәгънәсе буенча куллану; Татар, рус язучы –шагыйрьләренең әсәрләрен башкарганда, сөйләгәндә сәнгатьле сөйләм формалаштыру, геройларга карата үз мөнәсәбәтләрен формалаштыру. |
| 5 | Нәфис-нәфасати үсеш | Татар музыкасын тыңлауда кызыксыну уяту. Музыкаль хәтерүстерү. Балаларны татар композиторларының музыкаль әсәрләренең жанрларын билгеләргә өйрәтү. Милли репертуар нигезендә балаларның җырлау сәләтләрен камилләштерү.<br>Классик, халык, заманча халык көйләре белән, халык уен коралларының: трещотка (рус), курай (башк.), волынка (“сарпай”- чув.), кубыз (тат) яңгыравы белән таныштыру.<br>Татар бизәге: канәфер, өчъяфрак белән таныштыруны дәвам итү.Татар халкының декоратив-кулланма сәнгате турында күзаллауларын киңәйтү (тукыма әйберләре, күн мозаика).Татар , рус халкының орнаменты һәм милли киемнәре турында күзаллауларын формалаштыру. Кәгаздә халык эшләнмәсе бизәкләре (поднос, чынаяк) кием һәм баш киеме(алъяпкыч, яулык, калфак,) һәм көнкүреш әйберләре(ковер, салфетка, сөлге) ясау теләге уяту. Актүбә һәм шәмордан уенчыкларын әвәләп ясау сәләтләрен үстерү һәм аларның үзенчәлекләрен күрсәтә белү (“Сабантуй”, “Өч кыз”, “Көянтәле кыз”). Балаларны татар кулланма сәнгате мотивлары буенча күмәк эш булдыруга җәлеп итү. Рәсемдә көнкүреш әйберләренең образларын, татар халык экиятләренең персонажларын һәм татар язучыларының экиятләрен ясап бирү сәләтләрен камилләштерү. Балаларны танылган рус пейзажисты И.И.Шишкинның иҗаты белән таныштыру (“Иртә нараtлык урманында”, “Арыш”). |

### 1.7. Көндәлек режим

| *Режим вакыты* | *Сәгате* |
|---|---|
| Балаларны кабул итү, тикшерү, һавада булу,уеннар, дежур тору | 6.00 – 8.00 |
| Иртәнге гимнастика | 8.00 - 8.06 |
| Иртәнге ашка әзерлек, ашау вакыты | 8.25 - 8.45 |
| Уеннар, турыдан-туры белем бирү эшчәнлегенә әзерлек | 8.45-9.00 |
| Турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге | 9.00 – 9.25<br>9.35-10.00 |
| Уеннар,урамга чыгарга әзерлек,<br>һавада булу | 10.00-12.00 |
| Урамнан керү, көндезге ашка әзерлек,<br>ашау вакыты | 12.00 – 12.20<br>12.20-12.50 |
| Көндезге йокыга әзерләнү, көндезге йокы | 12.50 – 15.00 |
| Йокыдан уяту, һава - су процедуралары, төштән соңгы аш | 15.00 -15.05<br>15.05-15-15 |
| Уеннар, мөстәкыйль эшчәнлек, түгәрәк эшчәнлеге, индивидуаль эш, турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге, хезмәт | 15.15 – 16.20 |
| Кичке ашка әзерлек, ашау вакыты | 16.20 – 16.40 |
| Матур әдәбият әсәрләре уку,саф һавага чыгу, түгәрәк эшчәнлеге, балаларны өйләренә озату | 16.40– 18.00 |

**1.8. 2021-2022 уку елына белем бирү эшчәнлеге челтәре**

| Зурлар төркеме №2 | | |
|---|---|---|
| дүшәмбе | 9.00-9.25 | Музыка |
| | 9.35 -10.00. | Танып белү (тирә-юнь белән таныштыру) |
| | 15.15-15.40 | Нәфис-нәфәсәти үсеш (рәсем) |
| сишәмбе | 9.00-9.25 | Рус теле |
| | 9.40 -10.05. | Физик үсеш |
| | 15.15-15.40 | Сөйләм үсеше (Сөйләм үстерү) |
| чәршәмбе | 9.00 -9.25 | Музыка |
| | 9.35 -10.00. | Танып белү (Иң гади математик күз.форм.) |
| | 15.15-15.40 | Нәфис-нәфәсти үсеш (рәсем) |
| пәнҗешәмбе | 9.00-9.25 | Әвәләү/кисеп ябыштыру |
| | 9.40 -10.05 | Физик үсеш (физик культура саф һавада) |
| | 15.15-15.40 | Сөйләм үсеше (Матур әдәбият уку) |
| җомга | 9.00-9.25 | Физик үсеш (физик культура залда) |
| | 9.35 -10.00 | Рус теле |
| чәршәмбе | Рус теле режим моментында | |

## II. Белем бирү юнәлешләре буенча комплекслы – тематик планнар

### 2.1 Танып белү үсеше.

**Бала һәм әйләнә-тирә дөнья.**

**Аңлатма язуы.**

**Предметлы һәм и социаль тирәлек.**

Балаларны төрле эшчәнлек аша зур булган предметлар дөньясы белән таныштыруны дәвам итү. Аларның функцияләрен атау.

Әйләнә – тирә турында алган белемнәре белән генә чикләнмичә, "дөньядагы бар нәрсә" белән кызыксына башлаулары өчен шартлар тудыру.

Көнкүреш предметларның сыйфаты, үзенчәлекләре белән таныштыруны дәвам итү, аларның төсен, формасын, зурлыгын, авырлыгын билгеләргә өйрәтү.

Әйберләрнең нинди материалдан (балчык, кәгазь, металл, тукыма, резина,пластмасса , пыяла. фарфор) ясалуы турында сөйләү. Кайбер предметларның билгеле бер материалдан гына эшләнергә тиешлеген аңлату.

Балаларны материал һәм аның вазыйфасы, корылма һәм аның вазыйфасы арасындагы бәйләнешне күрә белергә өйрәтү. Предмет һәм аның файдасы (урындыкка караганда кәнәфигә утырып ял итү уңайлырак һ. б.) арасындагы сәбәп – нәтиҗә бәйләнешен билгели белергә өйрәтү.

Балаларның теге яки бу әйбернең ничек һәм кайда эшләнгәнлеген беләсе килү теләген хуплау.

Предметның тарихы белән (үткәне һәм бүгенгесе) кызыксыну уяту.

Балаларның җәмәгать транспорты (автомашина, автобус, поезд, очкыч (самолет). теплоход) турындагы белемнәрен арттыру.

Җәмәгать урыннарында үз – үзеңне тоту кагыйдәләрен өйрәнү.

Мәктәп турында беренче күзаллау булдыру.

Театр, цирк, зоопарк, вернисаж турында, анда эшләүчеләр турында белемнәрне киңәйтү.

Балаларның тормыш тәҗрибәсенә таянып, авыл һәм шәһәр тормышы турында элементарь күзаллау булдыру.

Профессияләр турында күзаллауны киңәйтү.

Тормыш – көнкүреш җиһазлары, кул хезмәтенең тамырдан үзгәрүен, уенчыклар тарихы нигезендә күзәтеп, тормыш турында күзаллауларын киңәйтү, тирәнәйтү.

### Табигать белән танышу

Балаларның күп төрле табигать күренешләре турындагы күзаллауларын киңәйтү. Алар арасындагы иң гади бәйләнешләрне(суытты – күбәләкләр, коңгызлар күренми башлады) ачыклау. Җиләк – җимеш, яшелчә, гөмбәләр белән танышуны дәвам итү.

Кайбер бөҗәкләрне өйрәнү: кырмыска, күбәләк, камка, коңгыз.

Бүлмә гөлләре турында белемнәрне тулыландыру (бальзамин, фикус, хлорофитум, яран, бегония, примула һ. б.), аларны үстерү алымнары белән танышу.

3- 4 –төрле агачны танып, исемнәрен истә калдыру (чыршы, нарат, каен, өрәңге)

Бакчага килүче кошларны күзәтү (карга, күгәрчен, песнәк, чыпчык, кызылтүш), кышын аларны туйдыру.

Кешеләргә, хайваннарга, үсемлекләргә яшәү өчен кирәк булган шартлар турында (һава, су, азыкһ.б.) өйрәнү.

Хайваннарны, үсемлекләрне саклау кирәклегенә төшендерү.

### Сезонлы үзгәрешләр

*Көз.* Табигатьтәге үзгәрешләрне күрә, аңлата белергә өйрәнү: суытты, яңгырлар еш ява, салкын җил исә, яфраклар коела, уңыш җыела, кошлар җылы якка китә. Алар арасындагы иң гади бәйләнешләрне (суытты – күбәләкләр, коңгызлар күренми башлады) ачыклау.Орлыклар җыюга тарту, ни өчен кирәклеген аңлату.

*Кыш.* Табигатьтәге үзгәрешләрне күрә, аңлата белергә өйрәнү, кыш белән көзне чагыштыру.Кошларнык кышкы тормышын күзәтү, исемнәрен белү, тану,аларга ярдәм итү, җимлекләр ясап, җим салып тору.Салкында суның бозга әйләнүен, карның җылы җирдә эреп суга әйләнүен күзәтү. Җепшек көннәрдә кардан төрле сыннар ясарга, тауда шуарга, хәрәкәтле уеннарга тарту.

*Яз.* Ел фасылларын тану, язның билгеләрен атау (кояш ныграк җылыта, агачларда бөреләр

ачыла башлады, яшел чирәм күренде, бөҗәкләр чыкты). Бакчаларда, басуларда язгы кыр эшләре турында күзаллаулар булдыру, Орлык чәчү, тишелү процессын күзәтү.

*Җәй.* Җәйге үзгәрешләрне күрә һәм атый белергә өйрәтү: күк йөзе зәңгәр, көн җылы, кояш кыздыра, кешеләр җиңелчә киенгән. Су коеналар, кызыналар.

Төрле эшчәнлек вакытында ком, таш, су, кызыл балчыкның үзлекләре турында белемнәрне тирәнәйтү.

Җәй көне күп җиләк – җимешнең өлгерүе, күп хайваннарның балалары үсүе турында белемнәрен ныгыту.

**“Танып белү” (Бала һәм әйләнә-тирә дөнья)белем бирү өлкәсенең тематик планы**

| № | Тема | Бурычлар | Файдаланылган әдәбият | Вакыты |
|---|---|---|---|---|
| | | **Сентябрь** | | |
| 1 | **Проект. Минем бакчам.**Балалар бакчасы буйлап сәяхәт | Балалар бакчасына карата ярату хисләре тәрбияләү; балаларның игътибарлыкларын, куелган максатны аңлый белү сәләтен үстерү; “Минем бакам дигән темага хикәя төзеп сөйләргә өйрәтү. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбнз 13 бит | |
| 2 | **Проект. Мин яратам сине, Татарстан.** “Туган ил кайдан башлана?” | Тәрбияче хезмәте турында күзалауларын киңәйтү,тәрбияче хезмәтенә ихтирам хисләре тәрбияләү. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 16 бит | |
| 3 | **Проект. Яхшы сүз- җан азыгы.** Өстәл театры. “Өч кыз”. Татар халык әкияте | Балаларда якыннарына, әти-әниләренә карата кайгыртучанлык, игътибарлылык сыйфатлары тәрбияләү.Әкияттәге образларны дөрес итеп бирә белү, хәтер сәләтен үстерү.Әдәби әсәрләр аша тирә-юньдәге вакыйгаларга дөрес бәя бирергә, үз фикерләрен башкаларга җиткерә белергә өйрәтү. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 19 бит | |
| 4 | **Проект. Абдулла Алиш иҗаты.** “А. Алиш-балалар язучысы.” | А.Алиш әсәрләренә кызыксыну уяту, язучы әкиятләре аша балаларда уңай сыйфатлар тәрбияләү. Балаларның фикерләү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен үстерү. А. Алишның тормыш юлын, иҗатын өйрәнүне дәвам итү. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 21 бит | |
| | | **Октябрь** | | |
| 1 | **Проект. Хуш киләсең, ямьле көз!**Бакча тирәли сәяхәт- “Җәйләр үтте, көзләр җитте.” | Балаларда көзге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек һәм кызыксынучанлык сыйфатлары тәрбияләү.Үзләштерелгән сүзлек запасына таянып агач, яфрак,үләннәрне, һава торышын тасвирлап сөйли белү күнекмәләрен үстерү.Күзәтүләрдән чыгып, нәтиҗә ясаганда исем ясагыч һәм сыйфат дәрәҗәләрен белдерүче кушымчалардан файдаланырга өйрәтү ( яшькелт, ямь-яшел, сап- | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 23бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | сары, зәп- зәңгәр һ. б.) | | |
| 2 | **Проект. Күз күчтәнәчләре**. Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт. "Күзге могҗиза". | Балаларда туган як табигатенә, яшелчәләргә карата сакчыл караш тәрбияләү.Балаларның иҗади күзаллауларын, күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен үстерү. Яшелчәләр турындагы белемнәрен системалаштыру, алган белемнәрен уен барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 26 бит | |
| 3 | **Проект. Икмәк-ашәү терәге.** "Игенче хезмәте белән танышу." | Балаларда игенче хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.Табышмаклар ярдәмендә күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү.Яңа очраган сүзләрнең мәгънәләрен аңлату, сүзлек запасын баету,  игенче хезмәтенең авыр һәм мактаулы эш икәнен аңлату. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 30бит. | |
| 4 | **Проект. Минем гаиләм, өем, йорт җиһазлары.**Үз тәҗрибәсеннән чыгып  хикәя төзү. "Безнең гаилә." | Балаларда гаилә әгъзаларына хөрмәт, ярату хисләре тәрбияләү. Образлы фикерләү сәләтен үстерү. Балаларның үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзүләренә ирешү. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 33 бит | |
| | | **Ноябрь** | | |
| 1 | **Проект. Табын янында.**Савыт-саба кибетенә сәяхәт. | Балаларда савыт- сабага карата сакчыл караш тәрбияләү. Балаларның күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен,  диалогик һәм монологик сөйләмен үстерү."Савыт- сабалар"  кибете турында белемнәрен тулыландыру, тәрбияче үрнәгендә кечкенә хикәяләр төзеп сөйләргә өйрәтү. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 41 бит | |
| 2 | Әңгәмә. "Мин кунак яратам." | Үзеңне әдәпле тоту күнекмәләрен тәрбияләү. Балаларның фикерне бер юнәлештә туплый белүләрен, сорауларга аңлаешлы итеп җавап бирә алу сәләтләрен үстерү. Милли ризыклар турындагы белемнәрен тирәнәйтү.Балаларны кунакчыл булырга, кунакларга хөрмәт күрсәтергә өйрәтү. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 43бит | |
| 3 | **Проект. Киемнәр дә безне бизиләр.** | Балаларда киемнәргә карата зәвык, сакчыл караш тәрбияләү. Тәрбияче биргән соруларга төгәл | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Кием- салым кибетенә сәяхәт. | җавап кайтара белү күнекмәләрен үстерү.Тормышта тышкы кыяфәтнең дә мөһимлеген аңлауларына ирешү.<br>Өс- баш, аяк киемнәрен чагыштырырга, төркемнәргә аерырга өйрәтү. | 49бит. | |
| 4 | **Проект. Саулык- зур байлык.**<br>“Су һәм кояш, безнең белән гел юлдаш”. | Балаларда үз сәламәтлекләренә карата игътибарлылык, сак караш тәрбияләү.Балаларның үз фикерләрен дөрес итеп җиткерә белү күнекмәләрен үстерү, сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш булдыру. Балаларга сәламәтлекне саклауда табигатьнең әһәмиятен аңлату, чыныгу чаралары белән таныштыру. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 49 бит. | |
| 5 | **Проект. Исеменә күрә - җисеме.**<br>Әңгәмә:” Исемең матур кемнәр куйган”. | Балаларда башка кешеләргә карата игътибар, исемнәргә кызыксынучанлык тәрбияләү. Логик фикерләүне, хәтер сәләтен, хәрәкәт активлыгын үстерү. Балаларга һәр исемнең аерым бер мәгънә белдерүе турында төшенчә бирү; үзеңнең дә һәм иптәшләреңнең дә исемен һәм фамилиясен кыскартырга, үзгәртергә, бозарга ярамаганлыгын аңлату. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 52 бит | |
| 1 | **Проект. Салкын кыш. Кышкы уеннар.**<br>Әңгәмә - “Без суыктан курыкмыйбыз”. | **Декабрь**<br>Кышкы табигатьнең матурлыгына соклана белү сыйфатларын тәрбияләү.Балаларның иҗади күзаллауларын, бәйләнешле сөйләмен үстерү.Кыш турында белемнәрен тирәнәйтү, авазларның дөрес әйтелешен ныгыту. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез, 56 бит | |
| 2 | **Проект. Бездә кышлаучы кошлар.**Балалар бакчасы тирәли экскурсия. - “Җимнәр сибәм кошларга.” | Балаларда кошларга сакчыл караш, кайгыртучанлык тәрбияләү. Чагыштыру, күзәтүчәнлек, кызыксынучанлык күнекмәләрен үстерү.Балаларның кошлар турында белемнәрен баету, өлкәннәр ярдәмендә җимлекләр куярга өйрәтү. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез, 61бит | |
| 3 | **Проект. Кыргый хайваннар.**<br>Зоопарка сәяхәт. | Кыргый хайваннарга карата кай гыртучанлык һәм зоопаркта үз-үзеңне тоту сыйфатлары тәрбияләү. Уеннар һәм тирә-юнь белән танышу | З.И.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 66 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | барышында балаларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Кыргый хайваннар һәм аларның үзенчәлекләре турында белемнәрен баету. | | |
| 4 | **Проект. Йорт хайваннары һәм кошлары.** Тема. Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү. - “Ишегалдында.” | Балаларда барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү. Аларны рәнҗетмәскә кирәклеген төшендерү.Балаларның бәйләнешле сөйләмен , бер- берсен тыңлый, башкаларның җавапларын тулылындыра алу сәләтен үстерү. Рәсемнәр аша балаларның йорт хайваннары һәм кошлары турындагы күзаллауларын системалаштыру, кешенең алар турында ничек кайгыртуын күзаллый белүне формалаштыру. | З.И.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 71бит | |
| 1 | **Проект. Транспорт.**Җир өсте,һава һәм су транспорты | **Гыйнвар**<br>Балаларда урамда игътибарлылык һәм транспорт хезмәткәрләренә ихтирам тәрбияләү. Транспорт турындагы күзаллауларын киңәйтү, фикерләү сәләтен үстерү.Балаларны транспорт төрләре белән таныштыруны дәвам итү, аларның исемнәрен истә калдыру, кулланылышын белү. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 74бит | |
| 2 | **Проект. Юл йөрү кагыйдәләре.** Машинайөртүче һәм җәяүлене кисәтүче кур-кынычсызлык билгеләре | Балаларда урамда, җәмәгать транспортында, торак зонасында үз-үзеңне тоту культурасын тәрбияләү. Юлларда күзәтүчәнлекне, фикерләү мөстәкыйльлеген, дикъкатьлелекне үстерү.Юл билгеләрен аера белү, юлда хәвефсезлек кагыйдәләрен өйрәтүне дәвам итү. Сүзлек:тыючы, боеручы, мәгълүмат бирүче, кисәтүче, хезмәт күрсәтү. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез 78 бит | |
| 3 | **Проект. Хезмәт төбе-хәзинә.**Төзелеш булган җиргә сәяхәт яки рәсем карау.- “Хезмәткә хөрмәт.” | Балаларның өлкәннәр хезмәте турында күзаллауларын киңәйтү,төзүчеләр хезмәте белән таныштыру. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез, 82 бит | |
| 1 | **Проект. Рәсәй – зур дәүләт.** | **Февраль**<br>Балаларда туган илне ярату, башка милләт вәкилләренә карата хөрмәт | З.М.Зарипова Туган телдә | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | "Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел!" | тәрбияләү.Балаларның хәтерен, логик фикерләү сәләтен, диалогик сөйләмен, кызыксынучанлыкларын үстерү. Балаларның Россиянең башкаласы Мәскәү турындагы белемнәрен баету, Россиянең символикасы турында мәгълүмат бирү. | Сөйләшәбез, 88 бит | |
| 2 | **Проект. Батырлыкта матурлык.** Тема: "Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар." | Балаларда кыю, батыр солдат булу теләге уяту, әтиләре, абыйлары белән горурлану хисе тәрбияләү. Ватанны саклаучылар турындагы күзалллауларын киңәйтү, бәйләнешле сөйләмне үстерү. Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар турында белем бирү, аларның мөһимлеген аңлату. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез, 90 бит | |
| 3 | **Проект. Заманча әкиятләр.** "Винни-Пух кунакка бара"- минем яраткан мультфильмым." | Балаларда башкаларның фикерләрен бүлдермичә тыңлый белү, дөрес итеп аралаша белү сыйфатлары тәрбияләү.Балаларның иҗади сөйләмен, үз тәҗрибәсеннән чыгып сөйли белү күнекмәләрен үстерү.Заманча мультфильмнарны таный белергә, аларның эчтәлеге буенча үз фикерләрен башкаларга җиткерә белергә өйрәтү. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез, 92 бит | |
| 4 | **Проект Әтием – горурлыгым.** Әтием һөнәре | Балаларның профессияләр турында белемнәрен системалаштыру. Әти кешегә ихтирам һәм хөрмәт тәрбияләү. | А.И.Камалова, И.И.Хәмитова һ.б. "Туган телем-бөек анам теле", 84 бит | |
| | | **Март** | | |
| 1 | **Проект. Кояш гомере телим мин, әнием сиңа!** Әңгәмә. - "Әни кирәк" | Балаларда әниләргә карата ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү. Балаларның логик фикерләү сәләтләрен , әниләргә карата игтибарлылыкларын үстерү. Сорау- җавап тибында аралашу аша, баланы булган белемнәренә таянып фикер йөртергә, гомумиләштерергә, аерып карарга һәм берләштерергә өйрәтү. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез, 93 бит | |
| 2 | **Проект.Без язны яратабыз.** Тема: Балалар бакчасы тирәли максатчыл күзәтү. | Туган ягыбызда була торган язгы табигать күренешләренә соклану хисләре тәрбияләү. Балаларның күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү. Максатчыл күзәтү аша балаларны язгы табигать күренеше белән таныштыру. | З.М.Зарипова Туган телдә сөйләшәбез, 96 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | Тема: Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау. | Балаларда бер- берсен игътибар белән тыңлый, иптәше сөйләгәнне тулыландыра, аның эшчәнлегенә дөрес бәя бирә белү сыйфатлары тәрбияләү. Халык авыз иҗаты белән таныштыру аркылы балаларның сүзлек байлыгын, диалогик сөйләмнәрен, хәтер, иҗади уйлау сәләтләрен үстерү.Яз турында эндәшләр, тизәйткечләр, әйтенүләр, сынамышлар өйрәтүне дәвам итү. | З.М.Зарипова . Туган телдә сөйләшәбез, 98 бит | |
| 4 | Тәҗрибә үткәрү. - “Суган утырту”. | Балаларда суган үстерү теләге тудыру, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү.Балаларның логик фикер йөртү күнекмәләрен үстерү. Суганның файдалы яшелчә икәне турында төшенчә бирү, суган үстерү турында белемнәрен тулыландыру. | З.М.Зарипова . Туган телдә сөйләшәбез, 101 бит | |
| | | **Апрель** | | |
| 1 | **Проект. Безнең канатлы дусларыбыз.** Тема: Терәк сораулар буенча рәсемгә карап, чагыштырма хикәя төзү. “Сыерчык белән карга яз килүгә шатлана.” | Кошларга сак караш һәм кайгыртучанлык хисе тәрбияләү. Балаларның күзаллау, тасвирлый белү сәләтен үстерү.Кошлар турында белешмә бирү, тышкы билгеләренә карап сыерчыкны һәм карганы танырга өйрәтү, кешеләрнең алар турында ничек кайгыртуын күзаллый белүне формалаштыру. | З.М.Зарипова . Туган телдә сөйләшәбез, 102 бит | |
| 2 | **Проект. Галәм киңлекләре.** Тема: Уен “ Планетарийга сәяхәт” | Балаларда беренче очучы, Ю. Гагарин белән танышу аша илебезгә карата горурлык хисләре тәрбияләү.Балаларның образлы күзаллауларын, иҗадилыкларын, хәтерен үстерү.Балаларга кояш системасы, планеталар турында элементар белешмә бирү, алар турында күбрәк беләсе килү теләге уяту. | З.М.Зарипова . Туган телдә сөйләшәбез, 117 бит | |
| 3 | **Проект. Су- яшәү чыганагы.** Тема: Әңгәмә. - “Яңгыркаем яу, яу!” | Табигатькә сак караш һәм мәхәббәт тәрбияләү.Балаларның фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен, игътибарлылыкларын үстерү. Табигатьтә була торган үзгәрешләр турында балаларның күзаллауларын киңәйтү, яңгырның каян килеп чыгуын аңлату.Табигатькә соклана | З.М.Зарипова . Туган телдә сөйләшәбез, 108 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | һәм аның гүзәллеген күрә белергә өйрәтү. | | |
| 4 | **Проект.Г.Тукай иҗаты.** Г. Тукайның тормышы һәм иҗаты” | Балаларда Г. Тукайның күпкырлы иҗатына кызыксыну уяту, ихтирам хисләре тәрбияләү.Шигырьнең эчтәлеге буенча үз фикерләрен әйтә белү, фикерләү, хәтер сәләтен үстерү.Г. Тукайның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыру, әдәби әсәрләрне тыңлый, эчтәлеген сөйли белүләренә ирешү. | З.М.Зарипова . Туган телдә сөйләшәбез, 118 бит | |
| | | **Май** | | |
| 1 | **Проект.Җиңү алып килде май.** Сугыш ветераннары белән очрашу.“Бөек җиңү” | Балаларда патриотик хисләр, туган якка, туган телгә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.Туган ил һәм дөньядагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкларын үстерү. Сугышчыларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында белемнәрен арттыру. | З.М.Зарипова . Туган телдә сөйләшәбез, 128 бит | |
| 2 | **Проект. Чәчәкләр-тормыш яме.** Уен –викторина. - “Чәчәкләр-тормыш яме” | Чәчәкләргә сакчыл караш, туган як табигатен өйрәнү теләге тәрбияләү. Мөстәкыйль фикерләү, фикерне бер юнәлештә җыя белү сәләтен үстерү. Балаларның чәчәкләр турындагы белемнәрен баету, чәчәкләрне танып белергә, тасвирлап сөйләргә өйрәтү. | З.М.Зарипова . Туган телдә сөйләшәбез, 129 бит | |
| 3 | **Проект. Урман-җиребезнең матурлыгы, байлыгы.**Урман почмагына экскурсия. | Балаларда урманга һәм аның байлыкларына сак караш тәрбияләү. Кешеләр тарафыннан табигатьне сакларга кирәклеге турында нәтиҗә чыгара белү, логик фикер йөртә белү сәләтен үстерү.Балаларның урман, андагы тереклек турындагы белемнәрен тирәнәйтү, мул табигатьнең кеше тормышында әһәмиятен аңлату. | З.М.Зарипова . Туган телдә сөйләшәбез, 122 бит | |
| 4 | Тема: .“Кызыл китап” нәрсә ул? | Кызыл китапка кертелгән хайван һәм үсемлекләрне кызгану, алар өчен борчылу хисләре уяту, табигатькә карата сак караш тәрбияләү.Балаларның әйләнә - тирә дөнья белән кызыксынуларын, бәйләнешле сөйләмнәрен үстерү. Балаларны сирәк калган һәм югалып бара торган хайваннар, үсемлекләр турындагы китап белән таныштыру, аның әһәмиятен аңлату. | З.М.Зарипова . Туган телдә сөйләшәбез, 125 бит | |

**Файдаланылган укыту-методик кулланма**

1.З.М.Зарипова. Туган телдә сөйләшәбез. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.
2.Туган телдә сөйләшәбез. Күрсәтмә һәм таратма рәсемнәр.
3. А.И.Камалова, И.И.Хәмитова һ.б. “Туган телем-бөек анам теле”, Яр Чаллы, 2004.

**Элементар математик күзаллаулар формалаштыру**
**Аңлатма язуы**
**Сан һәм санау.**

Балалар унга кадәр санарга өйрәнәләр, саннарны урыннарына карап чагыштыралар, санның берәмлекләрдән торган составы белән танышалар, санның микъдари һәм тәртип мәгънәсен аңлый башлыйлар. Балалар исәпләргә, санап алырга, предметларның исәбен
карточкаларга һәм рәсемнәргә карап белергә, хәрәкәт һәм авазлар буенча исәпләргә өйрәнәләр. Бөтен һәм өлешнең үзара мөнәсәбәтләрен ачыклыйлар, вакыт һәм пространствода дөрес ориентлашырга өйрәнәләр.
Балаларга күплек сандагы әйберләрне билгеләре(төсе, формасы, үлчәме) төрле булган аерым – аерым предметлардан төзергә мөмкин булуын төшендерү; тигез һәм тигез булмаган төркемнәрне чагыштырырга (предметларны парлап кую юлы белән)өйрәтү.
Предметларның ике төркемен чагыштырырга өйрәтү (1-2, 2-2, 2-3, 3-3, 3-4, 4-4, 4-5, 5-5)
һәм санау нигезендә төркемнәрнең тигез санда булуы яки азрак яисә күбрәк булуы турында күзаллау формалаштыру (“Монда бер, ике куян, ә биредә бер, ике, өч чыршы. Чыршылар куянга караганда күбрәк. Өч икедән күбрәк, ә ике өчтән азрак”). Тигез булмаган төркемнәрне ике ысул белән: төркемгә бер (җитешмәгән предмет өстәп яки күбрәк төркемнән бер (артык) предметны алып тигезләргә өйрәтүне дәвам итү).
Зуррак төркемнән беркадәр (яисә күрсәтелгән үрнәк буенча) предметларны аерып алырга өйрәтү (3 куян. 4 этәч санап алып кил).
Предметларны капшап карап, ишетеп санарга өйрәтү, хәрәкәтләрне саный белү күнекмәләре бирү.

***Зурлык***

Ике предметны зурлыгына (озынлыгына, киңлеге, биеклегенә, юанлыгына) карап берсе
өстенә (астына) берсен, берсе янына икенчесен кую юлы белән чагыштыра белүләрен камилләштерү; чагыштыру нәтиҗәләрен сөйләмдә чагылдыру (озынрак – кыскарак, киңрәк – таррак, биегрәк – тәбәнәгрәк).
Зурлыкны күрсәтүче ике билге буенча (кызыл тасма яшел тасмадан озынрак һәм киңрәк) предметларны чагыштырырга өйрәтү.
Балаларны төрле озынлыктагы, киңлектәге, биеклектәге берничә (5 кә кадәр) предметны арта һәм кими бару тәртибендә урнаштырып чагыштырырга, предметларның урнашу тәртибен (“иң биек чыршы, тәбәнәгрәк, тагын да тәбәнәгрәк, иң тәбәнәк”) күрсәтергә өйрәтү.

*Форма*

Геометрик фигуралар турында (шар, куб, цилиндр, түгәрәк, өчпочмак) күзаллауларын киңәйтү. Күреп, капшап, фигураларның төп билгеләрен (почмаклы, почмаксыз; тотрыклы, тотрыксыз; хәрәкәтчән. хәрәкәтсез)әйтә белү.
Балаларны турыпочмаклык белән таныштыру, аны түгәрәк, квадрат, өчпочмак белән чагыштыру. Турыпочмаклыкны таныргa һәм әйтергә өйрәтү.
Фигураларның төрле үлчәмдә була алуын аңлату: зур – кечкенә куб,
Бала пространствода ориентлаша белә һәм пространствоара мөнәсәбәтләрнең күпкырлы билгеләмәләрен дөрес куллана: «аска төшәргә кирәк, уңга борылабыз, почмакка кадәр барып җитәбез, сулга борылабыз, икенче якка чыгабыз».
Балаларны юнәлешләр билгеләргә, әйтелгән юнәлештә (алга - артка, өскә – аска, уңга - сулга)хәрәкәт итәргә; баланың үзенә карата предметларның торышын сүзләр белән

(минем алдымда - өстәл, артта – шкаф, уң ягымда – ишек, сул ягымда – тәрәзә) аңлатып бирергә өйрәтү.

*Вакытта ориентлашу.*

Тәүлекнең бүленеше (иртә, көндез, кич, төн), тәүлек вакытларының эзлеклелеге турында баланың күзаллауларын киңәйтү. *Кичә, бүген, иртәгә* дигән төшенчәләр белән таныштыру. Бу сүзләрнең мәгънәләрен аңлату.

Биш-алты яшьлек балада сөйләмле-логик фикерләү формалаша башлый, ул мантыйк үсешен һәм сүзләрне сөйләмдә нәтиҗәле куллануны үз эченә ала. Балалар мөстәкыйль фикерләргә, нәтиҗәләр ясарга, тиңләштерергә, чагыштырырга, анализларга, гади закончалыкларны кабул итәргә, аерым һәм уртак булган төшенчәләрне аңларга өйрәнә. Бала дөнья турындагы мәгълүматны аңлап һәм тирәнрәк итеп кабул итә башлый. Акыл эшчәнлегенең мантыйкый ысуллары - чагыштыру, гомумиләштерү, анализ, синтез, классларга аеру, серияләштерү, охшашлыклар табу, системалаштыру, абстрактлаштыру.

*Серияләштерү* - предметларны билгеле бер сыйфатлары буенча сайлап алып, аларны үсә бару йә кими бару тәртибендә урнаштырт.

Классик мисал: матрешкалар, пирамидалар, җыелмалы уенчыклар Һ.б

*Анализ* - объектның үзлекләрен аерып чыгару, яки объектны төркемнән аеру, яки бер төркем объектларны билгеле бер үзлекләренә карап аеру.

*Синтез* - төрле элементларны (билге, үзлекләр) бөтенгә берләштерү. Психологиядә анализ һәм

синтез бер-берсен тулыландыручы процесслар буларак карала (анализ синтез аркылы, ә синтезанализ аркылы башкарыла).

*Чагыштыру* — ул объектның (предмет, күренеш, предметлар төркеме) охшашлыгын яки

аермасын билгеләү буенча акыл эшчәнлегенең логик алымы. Баланың чагыштыру алымын тулысынча үзләштерүенең төп күрсәткече булып олы кеше күрсәтмәләреннән башка гына аны куллана белүе санала.

*Классификацияләү* - күплекләрне билгеле бер билгеләре бу-енча төркемнәргә аеру. Күплек аз күплекләрдән тора. Бу аз күплекләр кисешмәскә һәм аларның уртак кыйммәтләре булмаска тиеш.

*Гомумиләштерү* — чагыштыру процессы нәтиҗәләрен сөйләм (вербаль) формасында оештыра белү. Мәктәпкәчә яшьтәге бала объектларны гомумиләштергәндә, аларның ике яки берничә уртак сый-фатын аерып чыгара. Мөстәкыйль эшчәнлек вакытында барлыкка килгән гомумиләштерү (болар - зур, болар - кечкенә; болар барысы - өчпочмаклар, ә болары - квадратлар һ.б.) бала тарафыннан нә-тиҗәлерәк кабул ителә.

**Эшчәнлекнең тематик планы**

| Атна | Тема | Бурычлар | Файдаланылган Әдәбият | Вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | №1.1саны һәм цифрасы.Зур, кечкенәрәк,кечкенә төшенчәләре. | **Сентябрь**<br>Ныгыту:<br>-1 саны һәм цифры турында белемнәрне ныгыту; -предметларны зурлыгы буенча чагыштыру һәм зур,кечкенәрәк, кечкенә төшенчәләрен сөйләмдә куллану;<br>-закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү.<br>Йөрәтү:<br>-1санын язарга;<br>-уку мәсәләсен аңларга һәм мөстәкыйль үтәргә өйрәтү.<br>Таныштыру:<br>-1саны кергән мәкальләр белән танышу;<br>-көзнең беренче ае *сентябрь* белән танышу.<br>Үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе формалаштыру. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 15 бит | |
| 2 | №2. 2 саны һәм цифры. «+», «-» билгеләре. | Ныгыту:<br>-2 саны һәм цифры турында белемнәрне ныгыту;<br>-1санын язу осталыгын ныгыту;<br>-математик табышмаклар чишүне ныгыту;<br>-математик табышмакның җавабын сан һәм «+», «-» билгеләрен кулланып язу осталыгын ныгыту;<br>-альбом битендә ориентлашу, геометрик фигараларның урнашуын сүз белән әйтә белүне ныгыту; | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 17 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | -2 саны кергән мәкальләр белән таныштыру;<br>- предметның формасын геометрик фигурага тәнгәл китерү күнекмәсен ныгыту.<br>Өйрәтү:<br>-2 санын язарга өйрәтү.<br>Формалаштыру:<br>- уку мәсьәләсен аңларга һәм мөстәкыйль үтәүне;<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсен формалаштыру. | | |
| 3 | №3.1,2,3 саннары һәм цифрлары.Квадрат. | Ныгыту:<br>-предметларның санын аңа кагылышлы цифр белән туры китерү;<br>- санау таякчыклары ярдәмендә квадрат төзү;<br>-квадрат һәм чәчкә рәсемен шакмаклы дәфтәрдә төшерү.<br>Өйрәтү:<br>-3санын язарга өйрәтү;<br>-закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү.<br>Таныштыру:<br>-шакмаклы дәфтәр;<br>-3саны кергән мәкальләр. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 20 бит | |
| 4 | №4.1,2,3,4 саннары һәм цифрлары.Түгәрәк. Зурлык. | Ныгыту:<br>-предметларның санын аңа кагылышлы цифр белән туры китерү;<br>- санау таякчыклары ярдәмендә квадрат төзү;<br>-квадрат һәм чәчкә рәсемен шакмаклы дәфтәрдә төшерү.<br>Өйрәтү:<br>-3санын язарга өйрәтү;<br>-закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү.<br>Таныштыру:<br>-шакмаклы дәфтәр; | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 22 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | Узган материалларга кызыклы уеннар | -3саны кергән мәкальләр.<br>Формалаштыру:<br>- уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль үтәү;<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе.<br><br>Узган материалны ныгыту. | Интернет ресурслар | |
| 1 | №5. 1,2,3,4,5 саннары һәм цифрлары. 5санының составы. | **Октябрь**<br>Өйрәтү:<br>-математик табышмакны чишү,җавабын «+», «-»билгеләре һәм саннар кулланып язу;<br>-6санын язу;<br>-тәртип сан 6га кадәр,ничә?ничәнче урында?сораулары на дөрес җавап бирү;<br>-закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү.<br>Формалаштыру:<br>- уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль үтәү;<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе.<br>Ныгыту:<br>-предметларның санын аңа кагылышлы цифр белән туры китерү, табышмаклар, закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 24 бит | |
| 2 | №6. 6саны һәм цифрасы.<br>«=», «+» билгеләре.<br>Озынлык. | Өйрәтү:<br>- математик табышмакларга җавап бирергә, саннар һәм билгеләр ярдәмендә карар язарга;<br>- 6 санын язарга;<br>-логик мәсьәләне чишәргә. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 27 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | №7. 4,5,6саннары һәм цифрасы.<,>,= билгеләре.Квадрат, өчпочмак. | Таныштыру:<br>- 6 саны белән;<br>- 6 саны составы белән.<br><br>Өйрәтү:<br>-математик табышмаклар чишү;<br>- предметларның санын аңа кагылышлы цифр белән туры китерү;<br>-санау таякчыкларыннан өчпочмак,өй тезү;<br>-шакмаклы дәфтәрдә өчпочмак ясау.<br>Ныгыту:<br>-3,4,5,6 саннарын язу.<br>Таныштыру:<br>-«<», «>»билгеләре.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 29 бит | |
| 4 | №8. 4,5,6саннары һәм цифрлары. | Өйрәтүне дәвам итү:<br>- предметларның санын аңа кагылышлы цифр белән туры китерү;<br>-табышмак эчтәлегендәге чагыштыруларны аңлау;<br>- закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү;<br>- уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль эшләү.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 31 бит | |
| 1 | №9.<br>1,2,3,4,5,0 саннары һәм цифрлары.<br>«-»билгесе. | **Ноябрь**<br>Өйрәтү:<br>- математик табышмакны чишү,җавабын «+», «-»билгеләре һәм саннар кулланып язу;<br>-закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү;<br>-0 санын язу; | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”,<br>32 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | -геометрик фигуралардан таныш предмет рәсеме ясау;<br>- уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль үтәү.<br>Таныштыру:<br>-«-»билгесе;<br>- 0 саны. | | |
| 2 | №10. 0,4,5,6 саннары һәм цифрлары. | Өйрәтү:<br>- арифметик мәсьәлә чишү,җавабын «+», «-»билгеләре һәм саннар кулланып язу;<br>- предметларның санын аңа кагылышлы цифр белән туры китерү;<br>- ике төркем предметлары арасында тигезлек урнаштыру;<br>- ике рәсемдә аерымлыклар табу.<br>Ныгыту:<br>->,<,- билгеләре, “уңда”, ”сулда”, ”алда”, ”артта” төшенчәләрен сөйләмдә куллану.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 35 бит | |
| | | **Декабрь** | | |
| 1 | №11.7саны һәм цифрасы.<br>Өлеш төшенчәсе. | Өйрәтү:<br>- математик табышмакны чишү,җавабын «+», «-»билгеләре һәм саннар кулланып язу;<br>-7 санын язу;<br>-тәртип саны;<br>- санау таякчыклары белән турыпочмаклык төзү;<br>-шакмаклы дәфтәрдә эшләү;<br>-квадратны 2, 4 өлешкә бүлү.<br>Таныштыру:<br>-7 саны, атна көннәре.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 37 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | күнекмәсе. | | |
| 2 | №12.1,2,3,4,5,6,7 саннары һәм цифрлары. 7санының составы. | Таныштыруны дәвам итү:<br>-7 саны ;<br>-7 санын ике кечкенә санны кушып табу;<br>-декабрь ае.<br>Ныгыту:<br>-1дән 7гә кадәр саннарны язу.<br>Уку мәсьәләсен аңларга һәм мөстәкыйль эшләргә өйрәтү.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 39 бит | |
| 3 | №13.1дән 8гә кадәр саннар һәм аларның цифрлары. | Өйрәтү:<br>-математик табышмак чишү,<br>җавабын «+», «-» билгеләре һәм саннар кулланып язу;<br>-8 санын язу;<br>- кушу,алу билгеләрен дөрес куллану;<br>-логик мәсьәлә чишү.<br>Таныштыру:<br>-8 саны;<br>-атна көннәре.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе.<br>Күнектерү:<br>-тәртип сан 8гә кадәр. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 41 бит | |
| 4 | №14.Тәртип буенча санау.8санының составы.Предметны 4 өлешкә бүлү. | Өйрәтү:<br>-8 санын ике кечкенә санны кушып табу;<br>-өлеш төшенчәсе, предметны 2-4 өлешкә бүлү;<br>- уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль эшләү.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 43 бит | |
| 5 | Узган материалларга | Узган материалны ныгыту. | Интернет | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | логик мәсьәләләр чишү, ИКТ уеннар уйнау | | ресурслар | |
| 1 | №15.Кушу һәм алуга мисаллар.Овал. | **Гыйнвар**<br>Өйрәтү:<br>-кушу һәм алуга мисаллар чишү;<br>- анализ һәм синтезга логик мәсьәләләр чишү;<br>-тирә-юньдә ориентлашу;<br>-шакмаклы дәфтәрдә овал ясау;<br>- уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль эшләү.<br>Кышның икенче ае гыйнвар белән танышу.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 45 бит | |
| 2 | №16.< ,> билгеләре; тәртип буенча санау. | Ныгыту:<br>< ,> билгеләрен дөрес куллану.<br>Өйрәтү:<br>-геометрик фигураларны танып-белү;<br>- уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль эшләү;<br>-ничә? Кайсы? Ничәнче урында ? сорауларына дөрес җавап бирү;<br>-тәртип сан.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 47 бит | |
| 3 | №17.1дән 9га кадәр саннар һәм цифрлар. | Өйрәтү:<br>- математик табышмак чишү;<br>-9 санын язу;<br>-атна көннәрен түгәрәкләр ярдәмендә билгеләү;<br>- закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү;<br>- уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль эшләү.<br><br>**Февраль**<br>Таныштыру: | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | №18.1дән 9га кадәр саннар һәм цифрлар. Биеклек. | -9 саны;<br>-атна көннәре.<br>Ныгыту:<br>-“иң биек-тәбәнәгрәк-тәбәнәк-иң тәбәнәк” төшенчәләре.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 50 бит | |
| 2 | №19. Тәртип буенча санау, чиктәш саннарны чагыштыру. | Өйрәтү:<br>-тәртип саны,чиктәш саннарны чагыштыру;<br>- предметларның санын аңа кагылышлы цифр белән туры китерү;<br>-7 һәм 8 санын чагыштыру;<br>-квадратны 2,4,8 өчпочмакка бүлү;<br>-логик мәсьәләләр чишү;<br>- уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль эшләү.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 53 бит | |
| 3 | №20.10саны һәм цифрасы. Трапеция. | Өйрәтү:<br>-математик табышмак чишү;<br>-10 санын язу;<br>- санау таякчыкларыннан трапеция төзү;<br>-шакмаклы дәфтәрдә трапеция ясау;<br>-ике охшаш рәсемдә аерма табу;<br>- уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль эшләү.<br>Таныштыру:<br>-10 саны;<br>-геометрик фигура-трапеция.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 55 бит | |
| | | Ныгыту:<br>-1дән 10га кадәр саннар | Колесникова | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | №21.1дән алып 10га кадәр саннар. 10санының составы.Биеклек. | язу;<br>-геометрик фигуралар:трапеция, түгәрәк,өчпочмак турында белемнәрне ныгыту.<br>Өйрәтү:<br>-саннар арасындагы бәйләнешне аңлау;<br>-10 санын ике кечкенә санны кушып табу;<br>- закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү;<br>-уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль эшләү.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 56 бит<br><br>Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, бит | |
| 1 | №22.Мәсьәләләр чишү. | **Март**<br>Өйрәтү:<br>-мәсьәләләр чишү;<br>- санны аңа кагылышлы цифр белән туры китерү; -,+ билгеләре;<br>-шакмаклы дәфтәрдә кораб ясау.<br>Язның беренче ае март белән танышу.<br>Тәртип саны, анализ һәм синтезга логик мәсьәләләр,санау таякчыклары белән эшләү.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 59 бит | |
| 2 | №23.Кушу һәм алуга мәсьәләләр чишү. | Өйрәтү:<br>-математик табышмакларны чишү,җавапларын саннар һәм билгеләр ярдәмендә язу,укып күрсәтү;<br>-анализ һәм синтезга логик мәсьәләләр чишү;<br>-санау таякчыкларыннан геометрик | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 60 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | фигуралар,символик предметлар төзү;<br>- уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль эшләү.<br>Тәртип санны куллануга күнегүләр ясау. Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | | |
| 3 | №24.Кушу һәм алуга мисаллар чишү. | Өйрәтү:<br>-кушу һәм алуга мисаллар чишү;<br>-7,8,9,10 санын ике кечкенә санны кушып табу;<br>-мәйданда ориентлашу(уңга-сулга,алга-артка төшенчәләре);<br>-шакмаклы дәфтәрдә эшләү.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”,<br>62 бит | |
| 4 | №25.Цифр һәм предметның<br>саны тәнгәл килүе. | Өйрәтү:<br>-предметларның санын аңа кагылышлы цифр белән туры китерү; >,< билгеләре;<br>-вакытта ориентлашу-атна көннәре;<br>-закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”,<br>64 бит | |
| 5 | 1-9 га кадәр саннарны язу | Шакмаклы дәфтәрдә саннар язуны ныгыту | | |
| | | **Апрель** | | |
| 1 | №26.Кушу һәм алуга мәсьәләләр чишү.<br>Дүртпочмаклык,<br>Алтыпочмаклык. | Өйрәтү:<br>-кушу алуга мәсьәләләр төзергә;<br>-охшаш якларын һәм аермаларын табу буенча логик мәсьәләләр чишү; | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”,<br>66 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | -дүртпочмаклык, алтыпочмаклык турында белемнәрне киңәйтү.<br>Язның икенче ае апрель белән танышу.Кышкы айлар турында белемнәрне ныгыту.<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе. | | |
| 2 | №27.Кушу алуга мәсьәләләр,тәүлек өлешләре.Зурлык. | Өйрәтү:<br>-математик табышмак чишү,җавабын язу;<br>-язганны укый белү;<br>-предметларның санын аңа кагылышлы цифр белән туры китерү;<br>-шакмаклы дәфтәрдә өчпочмаклардан песи рәсеме төзү;<br>- “зур”, “кечкенәрәк”, “ иң кечкенәсе” төшенчәләрен сөйләмдә куллану;<br>-уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль эшләү.<br>Ныгыту:<br>-тәүлек өлешләренең (иртә,көн кич,төн) эзлеклеге.Күз чамасын үстерүгә күнегүләр ясау. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 68 бит<br><br>Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, бит | |
| 3 | №28.Мәсьәләләр чишү,атна көннәре, ел фасыллары. | Өйрәтү:<br>-математик табышмак чишү,җавабын язу;<br>-язганны укый белү;<br>-уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль эшләү;<br>-уйлау сәләтен үстерү.<br>Тәртип буенча санау күнекмәләрен ныгыту. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 70 бит | |
| 4 | №29.Мәсьәләләр чишү. | Өйрәтү:<br>- математик табышмак чишү,җавабын язу, язганны укый белү;<br>- анализ һәм синтезга логик мәсьәләләр чишү;<br>-уку мәсьәләсен аңлау һәм мөстәкыйль эшләү. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 71 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Ныгыту:<br>-10 санын ике кечкенә санны кушып табу;<br>- кәгазь битендә ориентлашу(“сулда өстә/аскы почмак”,”уңда өске/аскы почмак”,”уртада” төшенчәләре).<br>Формалаштыру:<br>- үз-үзеңне контрольдә тоту һәм бәяләү күнекмәсе.<br><br>**Май**<br>Санау һәм тәртип саннарын аера белергә өйрәтү;<br>- сорауларга җавап бирү: Күпме? Исәп буенча ничәнче урында?;<br>- шакмакта бака рәсемен урнаштыру;<br>- яңа материал-ны үзләштерү;<br>-сөйләм, язу, уку эшчәнлеге эшчәнлеген оештыра белү.<br>Беркетү:<br>-математик табышмакларга җавап бирә белү, язу һәм язу укый белү;<br>Үз-үзеңне тикшерү һәм үзеңә бәя бирү күнекмәләрен формалаштыру. | | |
| 1 | №30. Мәсьәләләр чишү. | | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”,<br>73 бит | |
| 2 | №31. Тәртип сан,мәсьәләләр чишү.Кабатлау | Ныгыту<br>-тәртип санын;<br>- сорауларга дөрес җавап бирә белү; күпме? исәп буенча ничәнче урында?<br>Өйрәтүне дәвам итү:<br>-10 санын ике сан ярдәмендә төзү, нәтиҗәләрен язарга;<br>-санау таякчыкларыннан предметларның символик сурәтләрен | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”,<br>75 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | (йорт, чыршы, лодка) төзү;<br>- логик мәсьәлә чишү;<br>- балыкның символик сурәтендә геометрик фигураларны күрергә; яңа материал-ны үзләштерү.<br>Үз-үзеңне тикшерү һәм бәя бирү күнекмәләрен формалаштыру. | | |
| 3 | №32. Мисаллар һәм мәсьәләләр чишү. | Уку бурычын аңларга өйрәтергә һәм аны мөстәкыйль башкарырга өйрәтү;<br>май ае белән танышу;<br>Үз-үзеңне тикшерү һәм бәя бирү күнекмәләрен формалаштыру. | Колесникова Е.В.”5-6 яшьлек балалар өчен математика”, 76 бит | |
| 4 | Диагностика | Балаларның ел дәвамында үзләштергән белем дәрәҗәләрен тикшерү | | |

**Файдаланылган әдәбият:**

Е.В.Колесникова “Математика для детей 5-6 лет”. - Москва, 2009.

**Конструкцияләү**

**Аңлатма язуы**

Балаларның игътибарын балалар бакчасы яки алар яши торган йорт тирәсендәге биналар һәм корылмаларга юнәлтү. Мәйданчыкта уеннар оештыру вакытында балалар белән машиналар, арбалар, автобуслар (башка транспорт төрләре) карау, аларның һәр өлешенең (кабинасы, тәгәрмәчләре һ. б.) формасы турында сөйләшү.

Балаларның төзелеш детальләрен (куб, пластина, борыс, кирпеч) тану һәм атый белү осталыкларын үстерүне дәвам иттерү, аларны төзелеш үзенчәлекләрен (формасы, ныклыгы, зурлыгы) исәпкә алып файдаланырга өйрәтү. Күргән корылмаларны искә төшереп, охшашлыклары буенча материаллар сайлап алу күнекмәләрен бирү.

Корылма үрнәкләрен анализларга: төп өлешләрен аера һәм зурлыклары буенча таный, бу аерым өлешләрнең бер – берсенә карата торышын( өйләрнең стеналары, түшәме, түбәсе; автомобильнең кабинасы, кузовы һ. б.) ачыкларга өйрәтү.

Тәрбияче күрсәткән конструкцияләү принцибын саклап (“Шундый ук өй төзе, ләкин биегрәк булсын”), корылманы биеклеккә, озынлыкка һәм киңлеккә мөстәкыйль үзгәртергә өйрәтү.

Вак һәм эре төзелеш материалларыннан төрле корылмалар төзү; төзелеш һәм аны бизәү өчен төрле төстәге детальләр файдалану.

Кәгазьдән конструкцияләргә: кырыйларын, почмакларын тәңгәл китереп, турыпочмаклы кәгазьне уртадан бөкләргә (альбом, мәйданчыкны бизәү өчен флагчыклар, котлау открыткасы),

төп формага детальләрен (өйгә - тәрәзәләр, ишекләр, морҗа; автобуска – тәгәрмәчләр; урындыкка аркасын) ябыштырырга өйрәтү.

Балаларны табигый материаллардан: агач кайрысы, ботаклар, яфраклар, күркәләр, чикләвекләрдән һ. б.әйберләр ясарга өйрәтү.

- корылма үрнәген күзәтеп, аны тасвирлап бирәләр, бу корылманы әзерләү этапларын планлаштыралар, конструктив алымнар табалар;
- рәсемнән карап, корылма төзиләр;
- конус, цилиндр, квадраттан эшләнмәләр әзерлиләр;
- әзер өлге буенча эшлиләр, шартлы билгеләрне аңлыйлар;
- кәгазь белән оригами ысулын (бөкләү, кат-кат бөкләү, киртекләп кисү) кулланып эшлиләр.

**Эшчәнлекнең тематик планы**

| № | Тема | Бурычлар | Файдаланылган әдәбият | Вакыты |
|---|---|---|---|---|
| **Сентябрь** | | | | |
| 1 | Төзелеш материаллары белән таныштыру | Төзелеш материаллары белән таныштыру | Л В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 13бит | |
| 2 | Йорт | Йорт корылмалары белән кызыксынуны формалаштыру | Л В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 19бит | |
| 3 | Цирк | Рәсемгә карап тәрбияче күрсәтмәсе буенча цирк бинасы төзергә өйрәтү. 19 бит | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 19бит | |
| 4 | Оригами | Кәгазьне дөрес бөкләргә өйрәтү. Кул–бармак моторикасын үстерү. | И.А. Фокина Искусство оригами 38 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | Оригами кабатлау | Кәгазьне төгәл бөкләргә өйрәтүне дәвам итү. Игътибарлылык тәрбияләү. | И.А. Фокина Искусство оригами 42 бит | |
| **Октябрь** | | | | |
| 1 | Җиңел машина | Машиналар төзү турында күзаллауларын формалаштыру. Рәсемгә карап тәрбияче күрсәтмәсе буенча җиңел машинасы төзергә өйрәтү | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 19бит | 1 атна |
| 2 | Йөк машинасы төзү | Машиналар төзү турында күзаллауларын формалаштыру. Рәсемгә карап тәрбияче күрсәтмәсе буенча йөк машинасы төзергә өйрәтү | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 20бит | 2 атна |
| 3 | Поезд | Поезд төзү турында күзаллауларын формалаштыру. Рәсемгә карап тәрбияче күрсәтмәсе буенча поезд төзергә өйрәтү | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 19бит | 3 атна |
| 4 | Оригами | Квадрат формасындагы кәгазьне бөкләү юлы белән уенчык куян ясарга өйрәтү. Аның вак өлешләрен (күз, борын) каләм белән ясау. | И.А. Фокина Искусство оригами 37 бит | 4 атна |
| **Ноябрь** | | | | |
| 1 | Самолет | Самолет төзү турында күзаллауларын формалаштыру. Рәсемгә карап тәрбияче күрсәтмәсе буенча самолет төзергә өйрәтү. Бер темага берләшкән конструкцияләр төзергә өйрәтүне дәвам итү. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 22бит | 1 атна |
| 2 | Ракета | Ракета төзү турында күзаллауларын формалаштыру. Рәсемгә карап тәрбияче күрсәтмәсе буенча ракетатөзергә өйрәтү. Бер темага берләшкән конструкцияләр төзергә өйрәтүне дәвам итү | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 27бит | 2 атна |
| 3 | Космик станция | Бер темага берләшкән конструкцияләр төзергә өйрәтүне дәвам итү | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 28бит | 3 атна |
| 4 | Оригами | Балаларны кәгазьдән бөкләп песи башын ясарга һәм аның күзләрен, авыз һәм мыекларын охшатып ясарга өйрәтү. | И.А. Фокина Искусство оригами 41 бит | 4 атна |
| **Декабрь** | | | | |
| 1 | Роботлар | Төзелеш материаллары кулланып конструкцияләү һәм модельләштерү. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 29бит | 1 атна |
| 2 | Роботлар | Рәсем буенча роботлар төзүне дәвам итү. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 30бит | 2 атна |
| 3 | Роботлар | Рәсемгә карап тәрбияче күрсәтмәсе | Л.В.Куцакова. | 3 атна |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | буенча робот төзергә өйрәтү. Бер темага берләшкән конструкцияләр төзергә өйрәтүне дәвам итү | Конструирование из строительного материала 31бит | |
| 4 | Роботлар | Логик фикерләү сәләтен үстерү. Кул – бармак моторикасын үстерү. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 31бит | 4 атна |
| **Гыйнвар** | | | | |
| 1 | Шәһәрчек төзү | Бер темага берләшкән конструкцияләр төзергә өйрәтүне дәвам итү. Корылманы төзү процессын планлаштырырга өйрәтү. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 34бит | 2 атна |
| 2 | Шәһәрчек төзү | Бер темага берләшкән конструкцияләр төзергә өйрәтүне дәвам итү. Корылманы төзү процессын планлаштырырга өйрәтү. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 27бит | 3 атна |
| 3 | Шәһәрчек төзү | Бер темага берләшкән конструкцияләр төзергә өйрәтүне дәвам итү. Корылманы төзү процессын планлаштырырга өйрәтү. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 27бит | 4 атна |
| **Февраль** | | | | |
| 1 | Күперләр | Күперләр турында күзаллауларын үстерү, күперләр конструкцияләү чишелешләре табарга ярдәм итү. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 37бит | 1 атна |
| 2 | Күперләр | Күперләр турында күзаллауларын үстерү, күперләр конструкцияләү чишелешләре табарга ярдәм итү. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 40бит | 2 атна |
| 3 | Күперләр | Күперләр турында күзаллауларын үстерү, күперләр конструкцияләү чишелешләре табарга ярдәм итү. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 42бит | 3 атна |
| 4 | Көчекнең гәүдәсен ясау (кәгазьдән кул эше) | Көчекнең гәүдәсен ясау алымнарын өйрәтү. Аңа башын куеп тулы уенчык барлыкка китерү. | И.А. Фокина Искусство оригами 64 бит | 4 атна |
| **Март** | | | | |
| 1 | Метролар | Метро төзергә кызыксыну формалаштыру. Корылма өчен нинди детальләр кулай булуын билгеләргә, аларны максатка яраклы итеп берләштерергә өйрәтү. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 43бит | 1 атна |
| 2 | Метролар | Метро төзергә кызыксыну формалаштыру. Корылма өчен нинди детальләр кулай булуын билгеләргә, аларны максатка яраклы итеп берләштерергә өйрәтү. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 43бит | 2 атна |
| 3 | Оригами | Кәгазьне бөкләп яңа уенчык | И.А. Фокина | 3 атна |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | “кошчык” ясарга өйрәтү. Бөкләмнәрне тигез эшләү. | Искусство оригами 75 бит | |
| 4 | Керамик плиткалар җыю | Балаларның фантазияләрен баету, детальләрдән узорлар җыю. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 44бит | 4 атна |
| **Апрель** | | | | |
| 1 | Корабль | Яңа төр уенчык ясарга өйрәтү. Корабльгә хас өлешләрен ясау. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 46бит | 1 атна |
| 2 | Корабль | Яңа төр уенчык ясарга өйрәтү. Корабльгә хас өлешләрен ясау. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 46 бит | 2 атна |
| 3 | Курчакка мебельләр | Балаларның фантазияләрен баету. Эш алымнарын ныгыту. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 46 бит | 3 атна |
| 4 | Курчакка мебельләр | Балаларның фантазияләрен баету. Эш алымнарын ныгыту | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 46 бит | 4 атна |
| **Май** | | | | |
| 1 | Архитектура һәм дизаин | Катлаулы корылмалар төзергә өйрәтүне дәвам итү. Аумаслык итеп төзүләренә ирешү, конструкцияләү сәлатләрен үстерү. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 50 бит | 1 атна |
| 2 | Башня | Катлаулы корылмалар төзергә өйрәтүне дәвам итү. Аумаслык итеп төзүләренә ирешү. | Л.В.Куцакова. Конструирование из строительного материала 46 бит | 2 атна |
| 3 | Үзең теләгәнне яса (төзелеш материал-лары белән конструк-цияләү) | Өйрәнелгәннәрне ныгыту. Төзелеш материалларыннан үзең уйлап ясауны камилләштерү. | Л.В. Куцакова Конструирование и ручной труд в детском саду. | 3 атна |
| 4 | Ишек алдындагы балалар өчен корылмалар | Балалар өчен төзелгән корылмалар төзергә өйрәтү (шуганак тау, йөрү өчен күперчек һ.б.). Фантазияләрен үстерү. | Л.В. Куцакова Конструирование и ручной труд в детском саду. 133 бит | 4 атна |

**Файдаланылган методик кулланмалар**

1. Л.В. Куцакова. Конструирование из строительного материала Мозаика – синтез Москва, 2014.

**2.2. Социаль -коммуникатив үсеш юнәлеше**

Балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү, үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру, балаларда хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм БЕЛЕМ БИРҮ БУРЫЧЛАРЫН билгели.

Балалар бакчасында балаларның (кечкенәләр, үзеннән зурраклар, яшьтәшләре, малайлар-кызлар, төркемгә килгән «яңа» балалар белән) туган телдә аралаша белү күнекмәләрен үстерү.

Төрле эшчәнлек төрләрендә балаларга туган телдә үзара һәм өлкәннәр белән бай, эчтәлекле аралашу өчен шартлар тудыру.

Элементар әхлак кагыйдәләренә өйрәтү, әхлак буенча аралашу үрнәкләре бирү, сөйләмдә татар халык фольклорын (мәкальләр, әйтемнәр, юаткычлар һ. б.) куллануга теләк уяту. Бөтен кешелек өчен уртак байлык булган патриотизм хисләренең әхлакый нигезен булдыру өчен шартлар тудыру (гаиләсенә, балалар бакчасына, туган ягына, иленә, әйләнә- тирә дөгел әргә мәхәббәт).

Гаиләң һәм аның тарихы турындагы күзаллауларны тирәнәйтү. Гаилә составы, туганнар (әти-әни, әби-бабай, абый-эне, апа-сеңел, туганнан туган абый-апалар), гаиләдәге урыны, туганлык җепләре һәм гаилә эчендә бәйләнешләр («Мин әтигә - ул, ә әбигә - оның», «Газизә апа - минем Фатыйма әбиемнең кызы»), әти-әниләрнең һәм туганнарның һөнәр һәм шөгыльләре турында күзаллаулар булдыру; туганнарның фотографияләрен карап, баланың әти-әниләре һәм башка туганнары белән тышкы охшашлыгына басым ясау. Сюжетлы-рольле уеннар өчен темалар төрлелеген хуплау; әйләнә-тирәдән, татар язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләреннән, телетапшырулардан, шәһәр (авыл) буенча
экскурсияләрдән, күргәзмәләрдән, походлардан алган белемнәргә нигезләнеп, сюжет үсешенә ярдәм итү.

Балаларның шартлы формада милли уенчыкларны, кулдан ясалган уенчыкларны файдаланган; тормышта булган хәлләрне, Идел буе халыклары әкиятләре сюжетларын, мультфильмнарны һ. б.ны чагылдырган шәхси һәм күмәк режиссерлык уеннарына булышлык күрсәтү.

Балаларның артистлык сәләтләрен үстерү, аларны сәхнә сәнгатенә тарту: концертлар кую, татар җырларын җырлау, Идел буе, халыклары биюләрен башкару, спектакльләрдән күренешләр күрсәтү. Яшьтәшләре, әти-әниләр һәм кунаклар алдында чыгыш ясарга мөмкинлекләр булдыру.

Инициативалылыкны, халык уеннары кагыйдәләрен үтәүне, тигез хокуклы партнёр позициясен ала белүне хуплау.

“Социаль- коммуникатив үсеш” юнәлеше җәмгыятьтәге әхлак һәм әдәп кануннарын үзләштерүгә юнәлгән.

Планлаштыру интеграция принциплары, төрле хезмәт һәм иҗат эшчәнлеге,
көнкүрештәге куркынычсызлык кагыйдәләре формалаштыру буенча төзелгән ( ФГОС ДО).

Татар халык әкиятләре («Өч кыз», «Үги кыз», «Һөнәрле үлмәс» һ. б.) ярдәмендә хезмәт эшчәнлеге турында күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү. Балаларның игътибарын әкияттә хезмәт итүче геройларга юнәлдерү. Балаларның эш барышларын Г. Тукай шигырьләрендәге («Кызыклы шәкерт», «Шаян песи» һ. б.) юллар белән бәйләү.

Туган шәһәрдәге (авылдагы) укытучы, врач, сыер савучы һ. б. һөнәр ияләре турында күзаллауларын формалаштыру.

Балалар бакчасы участогында тәрбияче белән эшләгәндә, балаларның актив катнашуын булдыру: яфраклар коелгач, кулларыннан килгәнчә участокны җыештыру, шәһәрдә яшәүче кошларга өстәмә азык бирү.

Гаилә бәйрәмнәренә әзерләнгәндә, өлкәннәргә кулларыннан килгәнчә булышу, өйдә үз вазифаларын үтәүгә тарту.

**Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру**

Балаларда мөстәкыйльлек, җаваплылык хисе үстерү; тормыш һәм сәламәтлекләрен саклау өчен, үз-үзеңне дөрес тотуның әһәмиятен аңлауларына ирешү.Таныш булмаган кешеләр белән мөмкин булган һәм очраклы очрашулар һәм аралашу барышында балаларда үзләрен ничек тотарга кирәклеге турында ачык күзаллау булдыру.

Таныш булмаган кеше белән үзең генә калу һич тә ярамавына һәм куркынычлыгына игътибарларын юнәлтеп, балалар белән шундый очраклы очрашулар вакытында килеп чыккан хәлләрне бергәләп карау һәм фикер алышу.

Юлларда хәвеф-хәтәрсез йөрү тәртибе формалаштыру.

Хәрәкәт юнәлешен (сүзле яки җаваплы) сигнал буенча алыштырып, «үзеңнән» һәм «үзеңә таба», бирелгән юнәлештә хәрәкәт итү; бер урыннан икенче урынга мөмкин булган күчешләр турында килешеп, әйләнә-тирәне үзләштерү; уен барышында объекттан (хәрәкәт итүче машина, поезд) хәрәкәт чагыштырмалылыгын билгеләргә өйрәтү.

Әйләнә-тирәдәге предметларның бер-берсенә карата булган урыннарын мөстәкыйль ачыклый белүләренә ирешү: өстенә - өстендә, буенча - астында, сулда - уңда, артында - алдында, янында, янәшәсендә, арасында, уртасында, өстәрәк - астарак. Тирә-юньдәге кешеләр һәм предметлар арасында үзеңнең торган урыныңны билгеләү күнекмәләре үстерү.

Светофорның төсләрен (ике яклы, җәяүле өчен), «Балалар», «Хәрәкәт тыела», «Җәяүлеләрнең хәрәкәте тыела», «Велосипедлар хәрәкәт итү тыела», «Велосипед юлы», «Хастаханә» һ. б. юл хәрәкәте билгеләренең зурлыгын, төсен һәм формасын, регулировщик таягының төсен ачыклау нигезендә, сенсор сиземләү күнекмәләре формалаштыру.

Балаларга югары куркынычлык зоналары турында сөйләү. «Тайгак юл», «Куркыныч борылыш», «Юл эшләре», «Кыргый хайваннар», «Шлагбаумлы тимер юл чаты» һ. б. кисәтүче юл билгеләре белән таныштыру, аларның охшаш һәм аермалы якларына игътибар итү.

Балаларны берничә полосалы хәрәкәт булган юлны чыгу алгоритмы белән таныштыру;юлларда, юл аркылы чыкканда, тәртипкә салына торган урам чатларын чыкканда ориентлашырга күнектерү. Балаларны «юл билгесе» төшенчәсе, юл чатларында җәяүлеләр хәрәкәтен тәртипкә сала торган «Җәяүлеләрнең җир асты юлы», «Җәяүлеләрнең җир өсте юлы» билгеләре белән таныштыру.

Хәрәкәтне сигналлар ярдәмендә җайга салучы ЮХИДИ инспекторы эшчәнлеге белән таныштыру, җәмгыять өчен аның хезмәтенең әһәмиятлелеген бәяләү күнекмәләре үстерү.

Балаларның махсус транспорт чаралары билгеләнеше («ашыгыч ярдәм» машинасы, «полиция» машинасы, «янгын сүндерү» машинасы һ. б.) турындагы белемнәрен ачыклау;

сигнал тавышларына игътибар итәргә, аларны аера белергә өйрәтү; кайбер аерым очракларда махсус транспорт чараларының юл йөрү кагыйдәләрен бозу мөмкинлегенә игътибар иттерү.

Метрода: вагонда (ишекләргә сөялмәү, чыгарга алдан әзерләнү), станциядә (бер юнәлештә хәрәкәт итү, тыелган сызыкка басмау), экскалаторда (уң якта басу, үз хәрәкәтеңне экскалатор хәрәкәтенә яраклаштырып керергә һәм чыгарга әзерләнү); турникетлар аша үткәндә үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләре белән таныштыру.

Метрода, юлларда, шәһәр (авыл) урамнарында үз-үзеңне куркынычсыз тотуның мөһимлеген аңларга ярдәм итү; әхлакый аралашу үрнәкләре («рәхмәт», «рәхмәтлемен сезгә», «гафу итегез», «рәхимле булыгыз», «мөмкин булмасмы» һ. б.) биреп, гади этикет кагыйдәләрен үзләштерергә булышу.

Җәмәгать урыннарында үз кыланышыңны һәм башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышын күзәтү, чагыштыру, каршы кую, бәяли белү күнекмәләрен үстерү;

балаларның юлларда үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләрен үтәмәгән очракта килеп чыккан күңелсез хәлләрне, аларның башка кешеләрнең эмоциональ халәтенә йогынтысын аңлауларына ирешү.

Үзең яшәгән җирлектә транспорт чараларының төрлелегендә ориентлашу күнекмәләрен үстерү: өйдән балалар бакчасына кадәр, үзәк мәйданга һ. б. җирләргә кадәр нинди маршрут автобусы белән барырга мөмкин, әти-әниләр нинди транспорттан файдалана һ. б.

Балаларны машинада утырып йөрү кагыйдәләре белән таныштыру: балалар урындыгында (креслосында) утыру һәм каеш белән эләктереп кую, машина йөртүченең игътибарын читкә юнәлдермәү, тәрәзәдән башны чыгармау, үзең белән очлы предметлар алмау; үз хәрәкәтләреңне контрольдә тотарга өйрәнү.

Баланы үз фамилиясен, тулы исемен, яшен әйтергә өйрәтү. Тору урынының адресын, телефонын, якындагы тукталыш исемен әйтү һәм полиция хезмәткәренә ярдәм сорап эндәшү күнекмәләрен булдыру.

Уңга һәм сулга борылышлар ясап, түгәрәк буйлап, елансымак, ике яки өч тәгәрмәчле велосипедта йөрергә өйрәнүне дәвам итү; үз хәрәкәтләреңне белән идарә итә белергә, велосипедта, самокатта йөрү урыннарын билгеләргә өйрәтү.

Балаларның хәрәкәтле уеннар, спорт һәм эстафета уеннары («Каршылыклы юл», «Күңелле ярышлар» һ. б.) оештыру инициативасын хуплау.

Балаларга таныш булган юл билгеләрен, урам чатлары, тукталышлар, ике яклы хәрәкәт, төрле билгеләнештәге транспорт хәрәкәтен файдаланып,җәяүлеләр һәм пассажирлар булып уй-нарга мөмкинлекләр бирә торган уен ситуацияләре тудыру һәм юл йөрү кагыйдәләрен үзләштерү өстендә эшләү.

Танып белү бурычларын үтәгәндә модельләштерү ысулын куллану: күләм һәм киңлек бәйләнешләрен билгеләү («Бүлмә буйлап сәяхәт», «Бала кая киткән?» һ. б.).

Чынбарлыкта булган, вербаль һәм вербаль булмаган уйлап чыгаруларга таянып, эчке программалаштыруның гади операцияләренә өйрәтү: ситуацияләрне уйнап күрсәтү, пространствода биналарның, транспорт чараларының, җәяүлеләр, юл билгеләренең урнашу макетын һәм моделен ясау күнекмәләре формалаштыру.

Алынган мәгълүматны (су, җир өсте, тимер юл, һава, җигүле транспорт)
гомумиләштерергә һәм аны мөстәкыйль эшчәнлектә файдалана белергә өйрәтү («Нәрсә артык?», «Автоюллар лотосы», «Юл доминосы» һ. б.).

Балаларның проблемалы характердагы сораулар бирүләрен хуплау, укыганнары буенча фикер алышуга теләк тудыру («Светофор эшләмәсә, нәрсә булырга мөмкин?», «Әгәр туп транспорт йөри торган юлга тәгәрәп чыкса, нишләргә?» һ. б.). Балаларны проблемалы ситуацияләрне чишәргә генә түгел, ә бәлки үз фикерләрен әйтеп бирергә өйрәтү.

Юлларда үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләренең кайберләрен ныгыту максатыннан, уйлап чыгарган әкиятләрдән, тормыш тәҗрибәләреннән алынган хикәяләр, шигырьләрдән, үзләре ясаган рәсемнәрдән (аппликацияләрдән) китап-җыентык төзүләрен хуплау.

Мәгълүматны мөстәкыйль рәвештә эзләп табарга мөмкинлек бирә.

**2.3 «Сөйләм үсеше »юнәлеше**

**Аңлатма язуы**

Сөйләм үстерү мохите.

Балаларның үзләрен әйләндереп алган гадәти тирәлектән читтә булган предметлар, вакыйгалар, күренешләр турында беләсе килү һәм алынган мәгълүматлар турында фикер алышуга ихтыяҗларын канәгатьләндерү. Кызыксынучанлыкларын үстерү.

Сүз байлыгын үстерү.

Әйләнә - тирә дөнья турындагы белемнәрен тирәнәйтү, предметлар, вакыйгалар, эш - гамәлләр турындагы күзаллауларын киңәйтү нигезендә, балаларның сүзлек запасын арттыру һәм активлаштыру.

Предметларның исемнәрен, аларның өлешләрен, детальләрен, нәрсәдән эшләнгәнбулуларын, кайбер материалларның яшерен үзенчәлекләрен (сына, ваклана, бөгәрләнә, ватыла) белдерүче сүзләрне сөйләмдә куллануны активлаштыру.

Еш куллана торган сыйфатларны, фигыльләрне, рәвешләрне, бәйлекләрне сөйләмдә кулланырга өйрәтү.

Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен, аларның эмоциональ халәтләрен белдерүче сүзләр белән балаларның сүзлекләрен баету. Сүзлекләренә һөнәрләрне белдерүче исемнәрне, эш – гамәлләрне чагылдыручы фигыльләрне кертү. Әйберләрнең кайда, ничек урнашуларын (уңда, сулда, ...), тәүлекнең кайсы вакыты булуын, кешеләрнең кәефен билгели һәм әйтә белергә өйрәтү эшен дәвам итү.

Сөйләмдә гомумиләштерүче сүзләрне (йорт җиһазлары, яшелчәләр, йорт хайванннары) кулланырга өйрәтү.

Авазларны дөрес әйтергә өйрәтү.

Тартык һәм сузык авазларның дөрес әйтелешен ныгыту; сызгырулы, чыжылдаучы, сонор (р, л) авазларын дөрес һәм ачык итеп әйтергә өйрәтү. Балаларның артикуляция аппаратын үстерү.

Дикция өстендә эшләүне дәвам итү; сүзләрне һәм сүзтезмәләрне ачык, дөрес итеп әйтә белүләрен камилләштерү. Фонематик ишетү сәләтләрен үстерү; билгеле бер аваз белән башланган сүзләрне ишетеп аера белү, сүзләр әйтү. Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Сөйләмнең грамматик төзелеше.

Балаларча сүзләр белән актив "тәҗрибә үткәрергә"мөмкинлек бирү, 5 яшькә чыккан балаларга хас булган яңа сүз ясау иҗатларын хуплау, сүзнең дөрес әйтелешен әдәпле генә искәртү. Җөмләдә сүзләрне бәйләргә өйрәнүне дәвам итү. Сөйләмдә бәйлекләрне дөрес куллану күнекмәләрен камилләштерү. Хайваннарның балаларын аңлаткан исемнәрне күплек санда һәм төрле килешләрдә куллана белү күнекмәләрен бирү.

Кайбер фигыльләрдән боерык фигыль ясау (киенә – киен) күнекмәләре булдыру.

Исемнәрне күплек санда куллана белүләрен камилләштерү.

Сөйләмдә тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрнең иң гади төрләрен кулланырга өйрәтү.

Бәйләнешле сөйләм.

Балаларның диалогик сөйләмен камилләштерүне дәвам итү. Актив рәвештә әңгәмәләргә катнашырга; сораулар бирергә, бирелгән сорауларга аңлаешлы итеп җавап бирергә өйрәтү.

Мөстәкыйль эшчәнлек процессында, балалар бер – берсе белән аралашканда, аларның аңлатмалы сөйләм куллануга омтылышларын хуплау.

Өлкәннәр кебек сөйләшү теләге тудыру, бирелгән сорауга дөрес җавап бирү бирелмәвен ачыклау омтылышын хуплау.

Предмет, картиналарны тасвирлап сөйләп бирергә өйрәтү (тәрбияче үрнәге буенча)

Таратма карточкалар кулланып, бала үзе төзегән картина буенча хикәя төзү күнекмәләре бирү ("Нинди матур урман килеп чыкты! Анда... яши, ... үсә" һ.б.)

Кечкенә әкиятләрне яисә әкиятләрдән балаларга ошаган өзекләрне сәхнәләштереп сөйли белү күнекмәләре бирү.

**Эшчәнлекнең тематик планы**

| № п/п | Тема | Бурычлар | Файдаланылган әдәбият | Вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Рәсем карау һәм хикәя төзү. “Балалар бакчасында.” | 1. Тәрбияче хезмәте турында күзаллауларын киңәйтү. Тәрбияче хезмәтенә ихтирам хисләре тәрбияләү.<br>2. Балаларның күзәтүчәнлекләрен, хәтерен, бәйләнешле сөйләмен үстерү.<br>3. Тәрбияче биргән план ярдәмендә рәсем буенча хикәя төзүләренә ирешү.<br>Дусларына һәрвакыт булышырга, ярдәмгә килергә кирәклеген төшендерү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 14 бит | |
| 2 | Башкалабыз-Казан. | 1. Туган якка мәхәббәт тәрбияләү.<br>2. Балаларның диалогик сөйләмен, игътибарлылыгын үстерү.<br>3. Татарстан башкаласы Казан турында белемнәрен тирәнәйтү, Татарстан символикасы һәм аның мәгънәсе белән таныштыру. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 17 бит | |
| 3 | Хикәянең эчтәлеген сөйләү.Ә. Бикчәнтәева. “Тәмле сүз”. | 1. Балаларга әсәрнең эчтәлегенә төшенергә булышу, матур әдәбият геройлары аша төрле начар сыйфатларга: дорфалык, үзен генә яратучанлыкка карата тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү.<br>2. Үзе һәм яшьтәшләре кылган эшләргә дөрес бәя бирә белү, фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен, монологик сөйләмне үстерү.<br>3. Проблемалы сораулар аша яхшылык, шәфкатьлелек, дуслык турында күзаллау бирү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 20 бит | |
| 4 | Рәсем буенча хикәя төзү. “Көзге табигать.” | 1. Балаларда бер- берсен тыңлый белү, кирәк урында тулыландыра белү сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Балаларның | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 24 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | игътибарлылыгын, рәсемдәге детальләрне күрә алу сәләтен үстерү.<br>3. Рәсем буенча хикәя төзеп сөйләргә ярдәм итү. | | |
| 5 | Сәхнәләштерү. В. Хәйруллина. “Яшелчәләр бәхәсе”. | 1. Балаларда матур әдәбият әсәрләренә кызыксыну тәрбияләү.<br>2. Артистлык сәләтләрен үстерү.<br>3. Тасвирлап сөйли белү күнекмәләрен ныгыту, шигырь эчтәлеген истә калдырырга ярдәм итү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 28 бит | |
| 6 | Әңгәмә. “Икмәк – тормышның нигезе”. | 1. Икмәккә сак караш тәрбияләү.<br>2. Балаларның игътибарлылыгын, хәтерен, фикер йөртә белү сәләтен үстерү.<br>3. Балаларга икмәкнең әһәмиятен аңлату, ипи үстерүдә катнашучыларның хезмәте турында белемнәрен ныгыту. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 31бит | |
| 7 | “Әби-бабайларны хөрмәтлик”. | Зурларга карата хөрмәт тәрбияләү, куелган сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 34 бит | |
| 8 | Әңгәмә. “Йорт җиһазлары”. | 1. Йорт җиһазларына сакчыл караш, аларны ясаучыларга хөрмәт тәрбияләү.<br>2. Танып белү эшчәнлеген, игътибарлылыкны үстерү.<br>3. Балаларның йорт җиһазлары турындагы белемнәрен баету, тирәнәйтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 38 бит | |
| 9 | Чагыштырма хикәя төзү. “Чәйнек белән самавыр.” | 1. Балаларда бер- берсен тыңлый һәм җавапларны тулыландыра белү сыйфаты тәрбияләү.<br>2. Эзлекле, бәйләнешле итеп чагыштырып тасвирлау хикәясе төзи алу күнекмәләрен камилләштерү, фикерне әйтә белү сәләтен үстерү.<br>3. Савыт- сабаны урынлы куллана белергә өйрәтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 42 бит | |
| 10 | Әңгәмә. “Милли киемнәр”. | 1. Халык сәнгате аша балаларда зәвык, матур итеп киенергә теләк тәрбияләү.<br>2. Балаларның логик фикерләү | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 47 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | сәләтен, сөйләм телен үстерү.<br>3. Милли киемнәргә кызыксыну уяту, үзләренә генә хас булган ачыклау, төсләрнең берләшүенә игътибар итү. | | |
| 11 | Сәхнәләштерү. А.Алиш. “Куян кызы” әкияте. | 1. Балаларда матур әдәбияткә кызыксыну, зурлар сүзенә колак сала белү сыйфатлары, сәламәтлеккә сак караш тәрбияләү.<br>2. Балаларның үзләре белгән әкиятләре буенча тамашалар уйнау осталыкларын, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү.<br>3. Балаларны тирә- юньдәгеләр кыен хәлдә калганын күрә белергә, ярдәмгә килергә, әкият образларын дөрес итеп бирә белергә өйрәтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 50 бит | |
| 12 | Без дә хокуклы. | 1. Балаларда уеннар аша бердәмлек, дуслык сыйфатлары, әхлаклылык тәрбияләү.<br>2. Балаларның кызыксынучанлыкларын, үзләренә, тирә -юньдәгеләргә карата игътибарлылыкларын, логик фикерләү сәләтен үстерү.<br>3.Кеше хокуклары турындагы матдәләрне матур әдәбият һәм рәсем- иллюстрацияләр аша балаларга аңлату, белемнәрен ныгыту. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 54 бит | |
| 13 | Рәсем буенча хикәя төзү “Кышкы уеннар”. | Балаларда узара дустанә мөнәсәбәт. Бер-берсен тыңлый белү сыйфатын тәрбияләү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 58 бит | |
| 14 | Рәсем карау “Кошлар килгән җимлеккә”. | Балаларда кошларга сакчыл караш тәрбияләү, ярдәм итәргә теләк тудыру. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 63 бит | |
| 15 | Рәсем буенча хикәя төзү “Куяннар”. | Балаларда бер-берсен тыңлый белү сыйфаты тәрбияләү, карау өчен бирелгән рәсем турында сөйлисе килү теләге булдыру. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 63 бит | |
| 16 | Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү “Ишек алдында”. | Балаларда барлык терлек ияләренә карата мәрхәмәтлек, кайгыртучанлык хисләре | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | тәрбияләү, йорт хайваннары һәм кошлары аша кайгыртучанлык хисе тәрбияләү. Сүзләрне активлаштыру: бозау, колын, көчек, чеби, бәбкә. | 71 бит | |
| 17 | Рәсем карау. “Песи һәм песи балалары”. | Бер-береңне игътибар белән бүлдермичә. Сабыр тыңлау сыйфатлары тәрбияләү. Хайваннарның һәм балаларның исемнәрен дөрес атау күнекмәләре бирү, хәрәкәтне белдерә торган сүзләрне ныгыту. Эчтәлекле рәсем буенча хикәя төзергә өйрәтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 72 бит | |
| 18 | Чагыштырып тасвирлау хикәясе төзү. “Йөк машинасы һәм җиңел машина”. | Балаларның бер-берсен бүлдермичә тыңлый белү, сыйфатлары тәрбияләү. Балаларның тасвирлап сөйли белү күнекмәләрен ныгыту, мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү. Балаларны тәрбияче биргән план буенча чагыштырып тасвирлау хикәясе төзергә өйрәтүне дәвам итү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 76 бит | |
| 19 | Әңгәмә. “Велосипед-минем дустым.” | 1. Балаларда юлда үз- үзеңне тоту культурасын тәрбияләү.<br>2. Бирелгән мәгълүматне тыңлый белү һәм үзләштерүне формалаштыру, мөстәкыйль фикер йөртә белү, коммуникатив сәләтләрен үстерү.<br>3. Велосипедта хәвефсез йөрү кагыйдәләрен өйрәтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 80 бит | |
| 20 | Әңгәмә. “Кем булырга?” | 1. Хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияләү.<br>2. Балаларның фикер йөртә белү сәләтен, диалогик сөйләмен үстерү.<br>3. Балаларның өлкәннәр хезмәте, аларның һөнәрләре турында белемнәрен киңәйтү. Алар хезмәтенең мөһимлеген аңлату. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез” 83 бит | |
| 21 | Әңгәмә. “Теле барның-иле бар.” | 1. Балаларда туган телебезне ярату, зурлау, аңа соклану хисләретәрбияләү.<br>2.Халык авыз иҗаты аша балаларның сөйләмен үстерү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 89 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 3. Мәкаль-әйтемнәрдәге төп фикерне аңларга, җырлаганда сүзләрне ачык итеп җырларга өйрәтү. | | |
| 22 | “Русча да яхшы бел, татарча да яхшы бел”. | Туган илне ярату, аның белән кызыксыну, туган илгә тугрылылык сыйфатларын тәрбияләү. Балаларның хәтерен, логик фикерләү сәләтен, диалогик сөйләмен, кызыксынучанлыгын үстерү. Балаларның Россиянең башкаласы Мәскәү турындагы белемнәрен ныгыту. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез” 88 бит | |
| 23 | “Минем яраткан спорт төре”. | Балаларда ихтыяр көче, уен кагыйдәләрен үтәү сыйфатлары тәрбияләү. Танып белү һәм мөстәкыйль фикерләү эшчәнлеген үстерү. Үз теләкләрен башкаларныкы белән яраклаштырырга, иптәшләре алдында җаваплылык хисе тоярга өйрәтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 106 бит | |
| 24 | “Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар”. | Ватанны саклаучылар турында күзаллауларын киңәйтү, бәйләнешле сөйләмне үстерү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 90 бит | |
| 25 | Әңгәмә “Әни кирәк”. | Әниләргә ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү. Әсәрнең эчтәлегенә, геройның эш-гамәленә карата мөнәсәбәтне белдерү һәм аны үз сүзләрен белән сөйләп бирү күнекмәләрен үстерү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез” 93 бит | |
| 26 | Рәсем буенча хикәя төзү. - ”Яз.” ( И. Н. Мурашковска методикасын кулланып.). | 1. Балаларда сөйләгәнне игътибар белән тыңлый белү, сорауларга төгәл җавап бирә белү сыйфаты тәрбияләү.<br>2. Әйләнә- тирә дөньяга эстетик мөнәсәбәт формалаштыру, бәйләнешле сөйләмне үстерү.<br>3. Балаларны табигатьтә була торган үзгәрешләрне күрә белергә өйрәтү, рәсем буенча сөйли белүләренә ирешү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез” 97 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 27 | Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау. | 1. Балаларда бер- берсен игътибар белән тыңлый, иптәше сөйләгәнне тулыландыра, аның эшчәнлегенә дөрес бәя бирә белү сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Халык авыз иҗаты белән таныштыру аркылы балаларның сүзлек байлыгын, диалогик сөйләмнәрен, хәтер, иҗади уйлау сәләтләрен үстерү.<br>3. Яз турында эндәшләр, тизәйткечләр, әйтенүләр, сынамышлар өйрәтүне дәвам итү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 98 бит | |
| 28 | Уен – викторина “ Кошлар – безнең дусларыбыз”. | Балаларда кошларга, барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү. Күзаллый, тасфирлый белү, уй-фикерләү сәләтен үстерү. Кошларның тышкы билгеләренә карап танырга, исемнәрен әйтергә өйрәтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 103 бит | |
| 29 | Тәҗрибә. “Суның үзенчәлекләре.” | 1. Яшәү чыганагы булган суга сак караш тәрбияләү.<br>2.  Балаларның күзаллауларын, мөстәкыйль фикер йөртә белү сәләтен  үстерү.<br>3. Гади тәҗрибәләр һәм уеннар аша балаларның су үзенчәлекләре  турындагы белемнәрен тирәнәйтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез” 110 бит | |
| 30 | Әңгәмә. “Янгын куркынычсыз - лыгы”. | Ут чыгу куркынычы булган әйберләр белән сак булу сыйфаты тәрбияләү. Балаларның уй-фикерләрен бер юнәлештә туплый белү, сәләтен, игътибарлыкларын үстерү.яңа сүзләр өйрәтү: янгын, ялкын, электр. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 111 бит | |
| 31 | Тәҗрибә. -“Кояш, су, һаваның үсемлекләр өчен әһәмияте.” | 1. Балаларда  үсемлекләрне күзәтә белү сыйфаты, тирә - юньгә кызыксынучанлык тәрбияләү.<br>2. Гади генә тәҗрибәләр ясап, балаларның хәтерен, игътибарлылылыгын, логик | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 115 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | фикерләү сәләтен үстерү, халык авыз иҗатына кызыксынуларын арттыру.<br>3. Балаларны белгән табигать күренешләрен күзәтеп, алар арасында үзара бәйләнеш булуы турында нәтиҗә чыгарырга өйрәтү. | | |
| 32 | Сәхнәләштерү. - Г. Тукай. “Бала белән күбәләк.” | 1. Балаларда Г. Тукай әсәрләренә карата кызыксыну тәрбияләү.<br>2. Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарлылыгын, иҗадилыкларын үстерү.<br>3. Балаларда оештыру һәм алып баручы ролен башкару осталыгын формалаштыру, үзләренең эш- гамәлләрен, уенны алып баручы һәм башка катнашучыларның гамәлләренә яраклаштырырга өйрәтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 120 бит | |
| 33 | “Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты”. | Балаларда Г.Тукайның күпкырлы иҗатына кызыксыну уяту, ихтирам хисләре тәрбияләү. Шигырьнең эчтәлеге буенча үз фикерләрен әйтә белү, фикерләү, хәтер сәләтен үстерү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез” 118 бит | |
| 34 | Камканы күзәтү. | 1. Балаларда табигатьтәге тереклек ияләренә карата сак караш тәрбияләү.<br>2. Образлы күзаллау сәләтен, күзәтүчәнлекләрен, диалогик сөйләмне үстерү.<br>3. Табигатьтә яшәүче бөҗәкләр белән таныштыруны дәвам итү. Камка турында үзләренең белгәннәрен бәйләнешле итеп сөйләргә өйрәтү. | Р.А.Борһанова “Татар телен өйрәнә нәниләр” 124 бит | |
| 35 | “Хуш исле нәфис гөлләр”. | Бүлмә гөлләренә карата сак караш тәрбияләү. Бәйләнешле сөйләм, чагыштырып фикерләү сәләтен үстерү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез” 114 бит | |
| 36 | Безнең гаиләдә кем, нәрсә эшли? | Сөйләмдә өченче зат, берлек сандагы фигыльләрне куллану, сөйләм телен үстерү. | З.Ф. Кашапова “Иң татлы тел- туган тел”, 276 бит | |
| 37 | Уен –викторина. “Чәчәкләр- | 1. Чәчәкләргә сакчыл караш, туган як табигатен өйрәнү теләге | З.М.Зарипова “Туган телдә | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тормыш яме". | тәрбияләү.<br>2. Мөстәкыйль фикерләү, фикерне бер юнәлештә җыя белү сәләтен үстерү.<br>3. Балаларның чәчәкләр турындагы белемнәрен баету, чәчәкләрне танып белергә, тасвирлап сөйләргә өйрәтү. | сөйләшәбез", 129 бит | |

**Файдаланылган методик кулланмалар**


1.З.М.Зарипова "Туган телдә сөйләшәбез", Казан ФОЛИАНТ, 2012 ел

2. К.В.Закирова "Балачак аланы" Казан РИЦ, 2011 ел

3. Ф.Ю.Юсупов "Гөлбакча", 1990 ел

4.К.В.Закирова "Иң матур сүз", Мәгариф нәшрияте, 2000 ел

**Матур әдәбият белән танышу.**
**Аңлатма язуы.**
Балаларны игътибар белән экиятләр, хикәяләр, шигырьләр тыңларга өйрәнүне дәвам итү.
Төрле алымнар һәм педагогик ситуацияләр кулланып, әсәрнең эчтәлеген дөрес аңлау, геройларның хәленә керә белү күнекмәләрен булдыру. Баланың соравы буенча экият, хикәя, шигырьләрнең аңа ошаган өзекләрен укып күрсәтү, әсәргә карата баланың шәхси мөнәсәбәтен булдыру.Әдәби әсәрләр белән кызыксынуын хуплау. Китаплар белән кызыксыну уяту юнәлешендә эшләүне дәвам итү. Балаларга таныш әсәрләрнең матур иллюстрацияле китап басмаларын күрсәтү. Китаптагы иллюстрацияләрнең мөһимлеген төшендерү (эчтәлек яхшырак аңлашыла; рәсемнәрне игътибар белән карасаң, күпме яңалык алып була һ.б.) Е. Рачев, Е. Чарушин, Ю. Васнецов рәсемнәре белән бизәлгән китаплар карау

**Эшчәнлекнең тематик планы**

| № п/п | Тема | Бурычлар | Файдаланылган әдәбият | Вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шигырь ятлау.М. Фәйзуллин. “Өлкән группага күчкәч.” | 1. Балаларда балалар бакчасына карата ярату хисләре тәрбияләү.<br>2. Балаларның хәтер сәләтен үстерү.<br>3. Шигырьгә кызыксыну уяту һәм ятлау теләге тудыру, һәр эшне вакытында эшләү кирәклеге турында аңлату. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 15 бит | |
| 2 | Шигырь уку. Р. Рәкыйпов. “Мин яратам сине, Татарстан.” | 1. Матур әдәбият әсәрләре аша балалар күңелендә туган илне сөю хисе тәрбияләү.<br>2. Балаларның тыңлый белү, үз фикерләрен башкаларга җиткерә белү сәләтен үстерү.<br>3. Туган як турында балаларның белемнәрен системалаштыру, сорауларга тулы итеп җавап бирүләренә ирешү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 18 бит | |
| 3 | Хикәя уку.<br>А. Алиш. “Каз белән Аккош”. | 1. А. Алишның әсәрләренә кызыксыну уяту һәм балаларда сәламәтлекне саклау,ныгыту кебек яхшы сыйфатларга карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.<br>2. Әсәрнең эчтәлеген аңларга булышу, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.<br>3. Балаларның тәрбияче биргән сорауларга төгәл җавап кайтаруларына, әсәрнең эчтәлегенә, геройларның эш-гамәленә карата мөнәсәбәтен | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 22 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | белдерү һәм аны үз сүзләре белән әйтүләренә ирешү. | | |
| 4 | Шигырь ятлау. Х. Халиков.“Күз.” | 1. Балаларда күзге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек сыйфатлары тәрбияләү.<br>2.Балаларның хәтер сәләтен, диалогик сөйләмнәрен үстерү.<br>3. Матур әдәбият белән балаларның кызыксынуын үстерү буенча алдагы эшчәнлектә башлаган эшне дәвам итү, шигырьнең эчтәлеген, катлаулы сүзләрне аңларга булышу. Шигырьне яттан сөйләргә өйрәтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 25 бит | |
| 5 | Шигырь ятлау. Х. Гарданов. “Түтәлләрдә үсте яшелчә.” | 1. Балаларда бер- берсен тыңлый белү сыйфаты тәрбияләү.<br>2. Балаларның хәтер сәләтен, игътибарлылыгын үстерү.<br>3. Матур әдәбият әсәрен сәнгатьле итеп сөйли белүләренә ирешү,сорауларга тулы җавап алу. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 29бит | |
| 6 | Әкият уку. “Икмәк” - төрекмән халык әкияте. | 1. Икмәккә сак караш, хөрмәт тәрбияләү.<br>2. Балаларның игътибарлылыкларын, хәтер сәләтен, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү.<br>3. Игенче хезмәте турындагы белемнәрен ныгыту, татар халкының хезмәт сөючән халык икәнен, ялкаулыкның бездә элек-электән зур кимчелек, начар сыйфат булуын, хезмәт сөю һәркемгә хас сыйфат булырга тиеш икәнен аңлату. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 32 бит | |
| 7 | Шигырь ятлау.Ә. Бикчәнтәева. “Дәү әнием.” | 1. Гаиләңне ярату, дәү әниләргә карата хөрмәт хисләре тәрбияләү.<br>2.Балаларның хәтер сәләтен, игътибарлылыгын, диалогик сөйләмен үстерү.<br>3. Шигырьне сәньгатле итеп сөйләү күнекмәләре бирү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 36 бит | |
| 8 | Шигырь уку. Ә. | 1. Балаларда әти кешегә карата | З.М.Зарипова | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Ерикәй. “Әти йорт төзи.” | ихтирам һәм хөрмәт тәрбияләү.<br>2. Балаларның диалогик сөйләмен, логик фикерләү сәләтен үстерү<br>3. Шигырьне игътибар белән тыңларга,эчтәлеге буенча тәрбияченең биргән сорауларына тулы җавап бирергә өйрәтү. Балаларның төзүче һөнәре турындагы белемнәрен системалаштыру. | “Туган телдә сөйләшәбез”, 40 бит | |
| 9 | Хикәя сөйләү. “Тәлинкәнең төбе нинди.” | 1. Балаларда савыт- сабаларга карата сак караш тәрбияләү.<br>2. Әсәрнең төп идеясен аңлый, геройларның кылган эшләренә дөрес бәя бирү күнекмәләрен, монологик сөйләмне үстерү.<br>3. Алган белемнәрен уен барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 45 бит | |
| 10 | Шигырь ятлау. Ә.Ерикәй. “Чисталык сөябез.” | 1. Шигырь аша балаларда чисталыкка омтылыш тәрбияләү.<br>2. Эзлекле һәм сәнгатьле итеп шигырьне сөйләү күнекмәләрен, хәтер сәләтен үстерү.<br>3. Балаларны гигиена кагыйдәләренә гадәтләнергә өйрәтү, чисталык- сәламәтлекнең нигезе икәнен төшендерү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 51 бит | |
| 11 | Хикәя уку. К. Ушинский. “Кыш әбинең шуклыгы.” | 1. Серле табигать күренешләренә соклану хисләре һәм мәхәббәт уяту.<br>2.Балаларның фикерләрен бер юнәлештә туплый белү сәләтләрен үстерү.<br>3.Кышкы салкын көннәрнең кошлар, хайваннар, кешеләр өчен иң авыр вакыт булуын ачыклау. Балаларны әдәби әсәр аша кышның тасвирланышы белән таныштыру. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 60 бит | |
| 12 | Шигырь ятлау.-Д. Гарифуллин “Песнәк.” | 1. Балаларда кошларга, барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү.<br>2. Шигырьне ятлау теләге | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 64 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | булдыру, хәтер сәләтен үстерү.<br>3. Балаларда шигырьне сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләре булдыру. | | |
| 13 | Шигырь уку.<br>Г. Лотфи.<br>“Балалар ярдәм итә.” | 1. Матур әдәбият аша балаларда мәрхәмәтлелек, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Балаларның диалогик сөйләмен, әйләнә- тирә мөхит үзгәрешләрен, бер- берсе белән бәйләнешен күрә белү сәләтен үстерү.<br>3. Авазларны ныгыту буенча эшне дәвам итү. Балаларның сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирүләренә ирешү, кышлаучы кошлар турында белемнәрен ныгыту. | З.М.Зарипова<br>“Туган телдә сөйләшәбез”,<br>65 бит | |
| 14 | Әкият уку, сәхнәләштерү. - “Төлке белән бүре” татар халык әкияте. | 1. Балаларда театр сәнгатенә мәхәббәт һәм эстетик зәвык тәрбияләү.<br>2. Балаларның үзләре белгән әкиятләре буенча тамашалар уйнау осталыкларын үстерүне дәвам итү, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү.<br>3. Сорауларга тулы җавап бирүләренә ирешү, әкиятнең эчтәлеген эзлекле итеп үз сүзләреӊ белән сөйләргә ярдәм итү. | З.М.Зарипова<br>“Туган телдә сөйләшәбез”,<br>69 бит | |
| 15 | Әкият уку.“Бүре аларны нигә ашаган”. Болгар халык әкияте. | 1. Балаларда халык авыз иҗатына уңай караш, әкият аша дуслык, бердәмлек сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Балаларның үз фикерләрен бер юнәлештә туплый белү сәләтен, хәтерен үстерү.<br>3. Әкият эчтәлеге буенча сорауларга тулы, аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү | З.М.Зарипова<br>“Туган телдә сөйләшәбез”,<br>70 бит | |
| 16 | Хикәянең эчтәлеген дәвам итеп сөйләү. - Г. Мөхәммәтшин. “Ак песи.” | 1. Балаларда игътибарлылык, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Балаларның иҗади күзаллауларын, фонематик ишетү сәләтен, бәйләнешле | З.М.Зарипова<br>“Туган телдә сөйләшәбез”,<br>73 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | сөйләмен үстерү.<br>3. Балаларга үз тәҗрибәләренә таянып хикәя төзергә, үз фикерләрен аңлаешлы итеп башкаларга җиткерергә ярдәм итү. | | |
| 17 | Хикәя уку.<br>И. Дәүләтшин "Алпамыш шәһәргә килде." | 1. Юлда үз иминлеген һәм башкаларның иминлеген кайгырту һәм саклау сыйфаты тәрбияләү.<br>2. Балаларның игътибарлылыгын, логик фикерләү сәләтен үстерү.<br>3. Матур әдәбият аша балаларның юл йөрү кагыйдәләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү һәм ныгыту. | З.М.Зарипова "Туган телдә сөйләшәбез", 77 бит | |
| 18 | Шигырь ятлау. - Ш. Галиев. "Светофорның өч күзе." | 1. Балаларда урамда, юлда үз-үзләрен дөрес тоту, бер-берсенә игътибарлы булу, сабырлык сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Шигырь аша светофор турындагы белемнәрен ныгыту, хәтер сәләтен үстерү.<br>3. Шигырьне яттан сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтү. Милиционер- регулировщик турында кыскача белем бирү. | З.М.Зарипова "Туган телдә сөйләшәбез", 77 бит | |
| 19 | Хикәя уку.<br>К.Ушинский. "Иртәнге нурлар." | 1. Матур әдәбият аша балаларда хезмәткә уңай сыйфатлар , ялкаулыкка тискәре караш тәрбияләү.<br>2.Балаларның хәтерен, игътибарын, сөйләм күнекмәләрен үстерү.<br>3. Әсәрнең эчтәлеге буенча үз фикерләрен башкаларга аңлаешлы итеп җиткерә белергә өйрәтү. | З.М.Зарипова "Туган телдә сөйләшәбез", 84 бит | |
| 20 | Шигырь уку.<br>В. Хәйруллина. "Табын кагыйдәләре." | 1. Балаларда кунакта үз-үзен тота белү сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Балаларның хәтер сәләтен, игтибарлылыгын , матур әдәбият әсәрләренә, халык авыз иҗатына карата кызыксынучанлыкларын үстерү. | З.М.Зарипова "Туган телдә сөйләшәбез" 86 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 3. Шигырь эчтәлеге буенча тәрбияченең биргән сорауларына тулы җавап бирергә, үз фикерләрен дөрес итеп башкаларга җиткерә белергә өйрәтүне дәвам итү. | | |
| 21 | Р.Миңнуллин. “Светофор” шигырен уку. | Балаларны юл кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү, җәяүлеләр өчен булган кагыйдәләрне аңлату. Шигырь аша юл билгеләре турында белемнәрен ныгыту. | А.И.Камалова, И.И.Хәмитова һ.б. “Туган телем-бөек анам теле”, 81 бит | |
| 22 | “Бал бабай” китабына сәяхәт. | “Бал бабай” китабына кергән регион язучыларының әсәрләренә күзәтү үткәрү. Шәһәребездә, регионыбызда яшәп иҗат итүче язучылар белән таныштыруны дәвам итү. | А.И.Камалова, И.И.Хәмитова һ.б. “Туган телем-бөек анам теле”, 83 бит.З.М.Зарипова, И.М.Хәмитов “Бал бабай” китабы” | |
| 23 | М.Җәлилнең “Сәгать” шигырен ятлау. | Балаларның сәнгатьле итеп, яттан шигырьләр сөйләүгә булган омтылышларын, хәтер сәләтен үстерү. | А.И.Камалова, И.И.Хәмитова һ.б. “Туган телем-бөек анам теле”, 84 бит | |
| 24 | Шигырь уку.<br>Җ. Дәрзаман. “Солдат булдым.” | 1. Илебезнең тынычлыгын саклаучы солдатларга карата патриотик хисләр тәрбияләү.<br>2. Балаларның хәтерен, диалогик сөйләмнәрен үстерү.<br>3. Шигырь эчтәлеге буенча сорауларга төгәл, кабатланмыйча, аңлаешлы итеп җавап бирергә өйрәтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 92 бит | |
| 25 | З.Гомәрова “Кояш елый” хикәясен сөйләү. | Матур әдәбиятка карата балаларның кызыксынуын үстерү. Әсәрнең эчтәлеге буенча тәрбияче биргән сорауларга җавап бирә белү күнекмәләрен камилләштерү. | А.И.Камалова, И.И.Хәмитова һ.б. “Туган телем-бөек анам теле”, 83 бит. | |
| 26 | Шигырь ятлау.<br>Н. Гайсин. “Әни гөлләре.” | 1. Балаларда, шигырьнең тылсымлы юллары аша, әниләргә карата мәхәббәт тәрбияләү.<br>2. Шигырьгә кызыксыну уяту, ятлау теләге тудыру, игътибарлылыкларын, хәтер сәләтен үстерү.<br>3. Авазларны, сүзләрне | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 95 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | ачыкэйтеп, сэнгатьле сөйләргә өйрәтү. | | |
| 27 | Шигырь ятлау.<br>М. Мазунов. “Яз килә.” | 1. Табигатьнең матурлыгын күрә, аңа соклана белү хисләре тәрбияләү.<br>2. Балаларның хәтерен, сәнгатьле итеп сөйли белү осталыкларын үстерү.<br>3. Аерым сүзләрне аңларга булышу, татар теленә генә хас авазлар кергән сүзләрне дөрес әйтүләренә ирешү. Шигырьгә кызыксыну уяту. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 100 бит | |
| 28 | Шигырь уку.<br>Г. Тукай. “Карлыгач.” | 1. Балаларда кошларга карата сак караш, мәрхәмәтлелек сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Әдәби әсәрләргә эмоциональ мөнәсәбәт формалаштыру, диалогик сөйләмне үстерү.<br>3. Балаларны игътибар белән шигырь тыңларга өйрәтүне дәвам итү. Шигырь аша кошларның үзенчәлекләре турында белемнәрен киңәйтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 105 бит | |
| 29 | Шигырь уку.<br>В.Хайруллина. “Туплар.” | 1. Балаларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.<br>2.Спортның төрләренә кызыксынучанлыкны, мөстәкыйльлекне үстерү.<br>3.Сөйләмдә грамматик формаларны һәм ясалма, мәгънәсе капма-каршы булган сүзләрне куллана белергә өйрәтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез” 107 бит | |
| 30 | Шигырь уку.<br>Г. Гыйльманов. “Ярый әле.” | 1. Матур әдәбият аша балаларда саклык , игътибарлылык сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Балаларның уй- фикерләү сәләтен, диалогик сөйләмен үстерү.<br>3. Балаларны җөмләләрдәге һәр сүзне үз урынына куеп, кушымчаларны дөрес ялгап әйтә белүләрен камилләштерү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез”, 112 бит | |
| 31 | Г.Тукайның “Су анасы” әкиятен уку. | Әкияткә каратакызыксыну уяту, эчтәлеген аңларга булышу. Әсәрнең эчтәлегенә, | А.И.Камалова, И.И.Хәмитова һ.б. “Туган телем-бөек | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | геройларның эш-гамәлләренә карата мөнәсәбәтеңне белдерү. | анам теле”, 90 бит. | |
| 32 | Г,Тукайның “Кәҗә белән сарык” әкиятенең эчтәлеген сөйләү. | Әкиятнең эчтәлеген бәйләнешле, эзлекле итеп, үз сүзләрең белән сөйләп бирергә өйрәтү. Игътибарлылык, иптәше сөйләгәнне тулыландыра белү сыйфатлары тәрбияләү. | А.И.Камалова, И.И.Хәмитова һ.б. “Туган телем-бөек анам теле”, 91бит. | |
| 33 | Шигырь ятлау.<br>З. Туфайлова.<br>“Тукай абый.” | 1. Шигырьнең тылсымлы сүзләре аша шагыйрьгә карата мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү.<br>2. Балаларның  үз теләкләре белән яттан шигырьләр сөйләүгә булган омтылышларын, хәтер сәләтен үстерү.<br>3. Шигырьдәге төп фикерне әйтә белергә өйрәтүне дәвам итү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез” 121 бит | |
| 34 | Әкият  эчтәлеген сөйләү.<br>Ф. Зариф. “Татлы җәй.” | 1. Җәйге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек һәм кызыксыну хисе тәрбияләү.<br>2. Балаларның сүзлек запасын арттыру, бәйләнешле сөйләм телен, фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен  үстерү.<br>3. Әкиятләргә кызыксыну уяту, сөйли белү теләге тудыру, аңларга өйрәтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез” 126 бит | |
| 35 | Шигырь уку.<br>Э. Шарифуллина.<br>“Минем бабай.” | 1. Балаларда патриотик хисләр, ватанга мәхәббәт тәрбияләү.<br>2. Шигырьнең эчтәлеге буенча сорауларга төгәл җавап кайтара белү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Балаларның бу шигырь аша Бөек Ватан сугышы геройлары турында күзаллауларын киңәйтү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез” 128 бит | |
| 36 | Хикәя уку.<br>Н. Фәттах.<br>“Велосипедлы Мөнир.” | 1. Балаларда  саранлыкка кире мөнәсәбәт  тәрбияләү.<br>2. Тәрбияче биргән сорауларга төгәл җавап кайтара белү күнекмәләрен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.<br>3.Балаларга  каршылыкларны мөстәкыйль рәвештә чишәргәөйрәтү, хикәя геройларына  дөрес бәя бирергә ярдәм итү. | З.М.Зарипова “Туган телдә сөйләшәбез” 131 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 37 | Сәмига Сәүбанова “Чәчәк” хикәясен уку. | Балаларны хикәянең эчтәлеген игътибар белән тыңлап аңларга өйрәтү.Тулы җөмләләр белән җавап бирергә күнектерү. | А.И.Камалова, И.И.Хәмитова һ.б. “Туган телем-бөек анам теле”, 94бит. | |
| 38 | Сабантуй бәйрәменә әзерлек. Шигырьләр өйрәнү. | Татар милли мәдәнияте белән таныштыруны дәвам итеп, Сабантуй бәйрәме турындагы күзаллауларын тирәнәйтү. Шигырьләр өйрәнү теләге тудыру. | А.И.Камалова, И.И.Хәмитова һ.б. “Туган телем-бөек анам теле”, 95бит. | |

**Файдаланылган методик кулланмалар**


1. Хәзрәтова Ф.В. Туган телдә сөйләшәбез. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2012.
2. А.И.Камалова, И.И.Хәмитова һ.б. “Туган телем-бөек анам теле”. – Яр Чаллы, 2004.

**2.4. «Нәфис-нәфасәти үсеш юнәлеше.**

**Иҗади сәнгать белем бирү өлкәсе**
**Рәсем ясау.**
- предметларның үзенчәлекле билгеләрен күрсәтеп ясый беләләр (натурадан, күз алдына китереп), сюжетлы композицияләр тудыралар;
- төрле композиция чаралары, сурәтләү материаллары кулланалар;
- халык декоратив-гамәли сәнгате үрнәкләре буенча бизәкләр төшерәләр;
- җылы Һәм салкын, караңгы һәм ачык төсләрне һәм аларның төсмерләрен аералар; гади төсмерләр ясый беләләр (ачыграк һәм сыеграк итеп).

Сюжетны ясаганда, эчтәлегенә һәм андагы объектларга туры китереп, сурәтләрне кәгазьбитендә дөрес урнаштырырга ярдәм итү. Балаларның тирә – юньдәге предметларның һәм табигать объектларының төсләре һәм төсмерләре турында күзаллауларын ныгыту һәм баету эшен дәвам итү. Таныш төсләргә һәм төсмерләргә яңаларын өстәү, бу төсләрне ничек китереп чыгару мөмкинлеге турында күзаллауларын формалаштыру.Төрле төсләр куллану теләге уяту, тирә – якның күп төслегенә игътибар иттерү.

Рәсем ясаганда гәүдәне төз тотып утыру күнекмәләрен ныгыту: өстәлгә бик якын иелмәскә, уңайлы итеп утырырга өйрәтү. Пөхтәлеккә күнектерү: эш урынында чисталык, тәртип саклау, эшне тәмамлаганнан соң, эш материалларын урынына алып кую.

**Эшчәнлекнең тематик планы**

| № | Тема | Бурычлар | Файдаланылган әдәбият | Вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Җәй | Җәй көне алган хисләрен рәсемдә чагылдырырга балаларны өйрәтү. Агачлар, чәчәкләр ясау, кәгазьнең аскы өлешенә җир, үлән ясау тәртибенә төшендерү. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 84 бит | |
| 2 | Акварель буяулар белән таныштыру | Балаларны акварель краскалар белән таныштыру, аның төсләренең үзенчәлекләрен аңлату. Төсләрне алыштырганда пумаланы чиста итеп юарга кирәк. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 86 бит | |
| 3 | Космея | Чәчкәнең тажларын һәм яфракларын дөрес итеп ясарга, төсләрне дөрес сайларга өйрәтү | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 86 бит | |
| 4 | Барысыннан да бигрәк нәрсә ясарга яратасың | Балаларны үзе ясый торган рәсемнең эчтәлеген уйлап табарга өйрәтү. Рәсем ясау алымнарын ныгыту. Эшне ахырына җиткерү теләге тәрбияләү. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 89 бит | |
| 5 | Тәлинкә | Тәлинкәдә татар бизәкләрен төшерү. Эстетик тәрбия бирү. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду, 92 бит | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 6 | Көзге күренеш | Төсле каләмнәр белән көзге төсләрне бирә белү. Зур һәм кечкенә агачларны ясауны өйрәтү. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 92 бит | |
| 7 | Бакчада алмалар читеште | Балаларны ботаклы җиләк-җимеш агачы ясарга өйрәтү. Буяулар белән ясауны ныгыту. Эстетик күзаллауны үстерү. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 87 бит | |
| 8 | Миләш ботагы | Миләш агачының сурәтен анализлау, аның төзелешенә игътибар бирү. Бармаклар белән эшләүне дәвам итү. | Р.Т.Казакова. Рисоание с детьми дошкольного возрата. 35 бит | |
| 9 | Дымка уенчыгы кәҗә бәтие ясау | Рәсемдә кәҗә сурәтен дымка бизәкләре белән бизәргә өйрәтү. Төсләрне дөрес куллану. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 95 бит | |
| 10 | Көзге урман | Көз көне алган кичерешләрне рәсеммдә күрсәтә белергә, төрле зурлыктагы агачлар (зур, кечкенә, төз, кәкре һ.б.) ясарга өйрәтү. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду, 91 бит | |
| 11 | Декоратив рәсем “Түгәрәктә-ге бизәк” | Түгәрәктә бизәк ясарга өйрәтү. Элементларын түгәрәк әйләнәли тигез урнаштыру һәм уртаны бизәү. Пумаланың очы һәм бөтен буе белән буяуны төшерү. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 92 бит | |
| 12 | Өч аю йөрергә чыкканнар | Балаларны әкият образларын ясарга өйрәтү. Гәүдә формаларын, өлешләрен, төзелешен бирә белү. Буяулар белән ясауны ныгыту. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 93 бит | |
| 13 | Күзаллап, уйлап ясау | Үзе теләгән предметны яки күренешне күзаллап ясау сәләтен үстерү. Гади графит каләм белән ясау һәм акварель белән буяуны ныгыту. | Т.С. Комарова . Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 97 бит | |
| 14 | Яңгыр ява | Тирә-юньдә алган кичерешләрне ршсемдә сурәтләргә өйрәтү. Композиция төзергә өйрәтүне ныгыту.Гади һәм төсле каләмнәр белән эшләргә өйрәтүне дәвам итү. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 94 бит | |
| 15 | Декоратив | Түгәрәктә бизәк ясарга өйрәтү. | Т.С. Комарова. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | рәсем “Түгәрәктә-ге бизәк” | Элементларын түгәрәк әйләнәли тигез урнаштыру һәм уртаны бизәү. Пумаланың очы һәм бөтен буе белән буяуны төшерү. | Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 99 бит | |
| 16 | Бәйрәмчә бизәлгән өй | Бер, күп этажлы өйнең формасын ясау һәм аны бәйрәмчә бизәү. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 100 бит | |
| 17 | Матур күлмәк кигән кыз | Кеше фигурасы ясарга, күлмәк формасы ясарга өйрәтү. Бөтен битне тутырып ясаргы өйрәтүне дәвам итү. Каләмнәр белән ясау һәм буяуны ныгыту. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду, 96 бит | |
| 18 | Әләмнәр белән бизәлгән автобус урамнан бара | Балаларны транспорт төренең төп өлешенең формасын ясау, аның чагыштырмача зурлыгын рәсемдә бирә белү. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 98 бит | |
| 19 | Декоратив рәсем (Дымка). Болан баласы. | Болан баласын дымка бизәкләре белән бизәү. Бизәкләрнең формаларын, төсен дөрес ясарга өйрәтү. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 102 бит | |
| 20 | Авылда төрле өйләр | Балаларны авылдагы төрле өйләрне: биек, озынчы итеп ясарга өйрәтү. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 102 бит | |
| 21 | Минем яраткан әкиятем | Яраткан әкиятнең күренешен үз рәсемеңдә бирә белү. Берничә персонаж һәм аның тирәлеген ясарга өйрәтү. | Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 101 бит | |
| 22 | Күзаллап, уйлап ясау | Үзең уйлап, күзаллап ясау сәләтен үстерү һәм ахырына җиткерү. Буяулар белән ясауны үстерү. | Т.С. Комарова . Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 103 бит | |
| 23 | Көз бүләкләре. | Балаларны көз “бүләкләре” (гөмбәләр, яшелчәләр, җиләк-җимешләр) ясарга өйрәтү, аларның формаларын, зурлыкларын дөрес итеп ясарга өйрәтү. | Т.С. Комарова . Занятия по изобразительной деятельности в детском саду | |
| 24 | Балалар | Рәсемне буяулар белән ясау | | |

